• МӘХӘЛЛӘ •
ГАИЛӘ БӘЙРӘМЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
*3 бит*

• МИНБӘР •
КЫРЫК ВӘҖИБ ГАМӘЛ ТУРЫНДА
*5 бит*

• СОРАУ–ҖАВАП •
ЯҢА ЙОРТКА КОРЪӘН УКЫТУ
*7 бит*

• БУ КЫЗЫКЛЫ •
СӨТ – АЛЛАҺЫНЫҢ БЕР БИЛГЕСЕ
*14 бит*

*№ 5 (286)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *рамазан – шәүвәл 1440*

*май, 2019*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# VII Республикакүләм ифтар



Рамазан аеның 20 көнендә, 2019 елның 25 маенда Казанда VII Республикакүләм ифтар узды.
Быелгы ифтарга ахшам намазына һәм авыз ачарга 15 мең кеше җыелды.

*Дәвамы 8-9 нчы битләрдә*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръән аятьләре булганлыктан, басмага игътибарлы булыгыз!

12+

# «Болгарга үзенең элеккеге бөеклеге һәм гүзәллеге яңадан кайтарыла»



*Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көне уңаеннан мөрәҗәгате*

Кадерле татарстанлылар!

Хөрмәтле ватандашлар!

Сезне истәлекле дата – Идел Болгарстанының Ислам динен рәсми кабул иткән көне уңаеннан чын йөрәктән тәбрик итәм!

922 елда Аллаһы Тәгаләнең бөек мәрхәмәте белән ата-бабаларыбызның күңеленә Ислам диненең илаһи нурлары иңдерелде һәм ул әлегәчә безне Ходайдан рәхим-шәфкать сорап, гөнаһлардан арынырга, рухи камиллеккә ирешергә, тынычлыкка һәм татулыкка өнди. Әлеге вакыйгадан соң унбер гасырга якын вакыт узган. Татарстанның барлык мәчетләрендә кебек үк, Борынгы Болгар җирендә бүген дә намазга чакырып, моңлы азан тавышы яңгырый. Әле күптән түгел генә ачылган Болгар ислам академиясендә мөселман мәгарифе һәм дин гыйлеме күтәрелеп килә.

Тамырларыбызга кайту безнең күңелләрдә шанлы тарихыбыз белән горурлану, үзенчәлекле мәдәниятебезгә, туган телебезгә чиксез хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре уята. Болгар диварларының борынгы ташлары данлы чорлар, каһарманнарыбыз һәм Ислам диненә багышланган хезмәтләре бөтен дөньяга мәгълүм булган, күренекле татар мәгърифәтчеләре эшчәнлегендә дәвам иттерелгән гыйлем ияләре турында хатирәләрне саклый. Шунысы куанычлы, дәүләт ярдәме һәм «Яңарыш» республика фонды, мөселман дин әһелләре, галимнәр һәм барлык ихлас күңелле кешеләр тырышлыгы белән рухи бишегебез – Болгарга үзенең элеккеге бөеклеге һәм гүзәллеге яңадан кайтарыла.

Ата-бабаларыбыздан калган бай дини мирасыбызны өйрәнү, саклап калу һәм үстерү эше хәзерге вакытта аеруча зур әһәмият ала. Идел Болгарстаны Ислам динен рәсми кабул иткән көнне билгеләп үтүнең быел изге Рамазан аена туры килүе әлеге игелекле миссияне башкаруга тагын да зуррак этәргеч бирер, дип ышанам.

Һәркайсыбыз бу бәйрәмне шәфкатьле һәм мәрхәмәтле эшләр һәм саваплы гамәлләр белән каршы алыр, дип ышанам.

Барыгызга да тынычлык, иминлек, бәхет телим!

■ **Татарстан Республикасы Президенты Р. Н. Миңнеханов**

# Нәзарәттә «Даруль-ифта» call-үзәге эшли башлады



Рамазан аеның беренче көнендә, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең яңа проекты – «Даруль-ифта» call-үзәге рәсми рәвештә эшли башлады.

«Даруль-ифта» – шәригатьнең теге яки бу мәсьәләләре буенча фәтвалар чыгару өчен махсус булдырылган күпканаллы call-үзәк. Теләге булган һәркем эш көннәрендә сәгать 10.00нан 16.00га кадәр **8 800 222 7667** номерына шалтыратып, үзен борчыган сорауларга җавап алырга мөмкин. Күпканаллы линиягә мөрәҗәгать итүчеләр белән шәригать белгечләре аралашачак. Call-үзәк Рамазан тәмамлангач та үз эшен дәвам итәчәк.

■ **dumrt.ru**

# «Мөселманнар – Россиянең бер йөзе!»

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Хөрмәтле ватандашлар, кадерле дин кардәшләр!

Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ!

Быел Идел буе Болгар дәүләтенең рәсми рәвештә Ислам динен кабул итүенә 1097 ел тула.

922 елның 21 мае – татар һәм бөтен Россия мөселманнары тарихында иң истәлекле көннәрнең берсе. Ул Исламның күп милләтләр өчен Ватан булып торган хәзерге Россия җирлегенә беренче үтеп кергән традицион дин булып торуын һәм төрле халыклар тарафыннан гасырлар буе тотылганын ассызыклый. Без яшәгән күп динле җәмгыятебезнең асылына Исламнан башка төшенеп булмаганга күрә, шулай ук бөек Россия милләте формалашуында дин кардәшләребез катнашканын да исәпкә алганда, шуны әйтә алабыз: мөселманнар – Россиянең бер йөзе!

Исламга хас булган игелек кылу, әхлаклы булу, белемгә, тынычлыкка һәм иминлеккә омтылыш кебек югары гуманистик кыйммәтләр безнең болгар бабаларыбызның күңеленә ачкыч таба һәм гомум Россия мөселман мәдәниятенә тирән тамырлар белән үтеп керә. Нәтиҗәдә, гасырлар аша узып, Ислам дөнья күләмендә уникаль күренеш – Россия мөселманнарының менталитетын формалаштыра. Гомер буе төрле мәдәниятләр һәм цивилизацияләр арасында яшәү, бай рухи мирас һәм Россия җәмгатьчелеге тормышында актив катнашу безнең мөселманнарга дөнья ислам цивилизациясендә алдынгы өммәтләр дәрәҗәсенә кадәр үсү өчен мөмкинлекләр тудыра. Безнең дин кардәшләребез күп гасырлар дәвамында ныклы күпер булып Россияне ислам дөньясы белән тоташтыра һәм илебезнең рухи тотрыклыгын тәэмин итүгә дә бәяләп бетергесез өлеш кертеп киләләр.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Бүгенге истәлекле көндә мин Россиянең барлык мөселманнарына мөрәҗәгать итеп, Аллаһы Тәгалә ризалыгына, өммәтебез һәм барыбыз өчен дә уртак булган Ватаныбыз хакына юнәлтелгән ихлас ниятләрдә һәм гамәлләрдә бердәм булырга чакырам. Раббыбыз безне төрле халыклар итеп яратса да, Исламда мөселманнар арасындагы рухи якынлык зур әһәмияткә ия. Коръәндә болай диелгән: **«Бу сезнең өммәт – бердәм өммәт. Мин исә – сезнең Раббыгыз. Миңа гына гыйбадәт кылыгыз!»** («Пәйгамбәрләр» сүрәсе, 92). Шулай итеп, барлык мөселманнар да иман белән берләшкән бердәм өммәт булып торалар.

Аллаһы Тәгалә болай дип тә боера: **«Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһы арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез! Янә Аллаһы сезгә биргән нигъмәтләрне күңелегездә саклагыз, ә бит мөселман булмас борын бер-берегезгә дошман идегез. Аллаһы Ислам дине белән күңелегезгә дуслык, өлфәт-мәхәббәтен салды да, бер-берегезгә дин кардәше булып әвереләегез»** («Әли Гыймран» сүрәсе, 100). Димәк ки, безнең халкыбызга Ислам динен – хакыйкать, гаделлек һәм игелек динен насыйп иткәне өчен, без Аллаһыга иксез-чиксез рәхмәтле булырга тиешбез.

Мин Раббыбыздан Россия һәм Татарстан өммәтенең чәчәк атуын, илебез өчен иминлек һәм бәрәкәт, шулай ук Аның безгә халык арасында ислам диненең бөеклеген һәм матурлыгын күрсәтеп, Коръәннең чын асыл мәгънәсен җиткерергә мөмкинлекләр бирүен сорыйм.

■ **Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Казанда хәйрия ифтары узды



Рамазан аеның 18 нче көнендә «Туган авылым» милли комплексында ТР Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды үз карамагындагы балалар өчен ифтар ашы оештырды. Рамазан ае уңаеннан уздырылган чарада 250 кеше катнашты. Кечкә ашка ДЦП диагнозлы, аутизм белән авыручы балалар, аларның әти-әниләре, ятимнәр, начар күрүчеләр, сукырлар, аз керемле һәм күп балалы гаиләләр җыелды. Кунаклар арасында мөфтинең рәсми органнар белән эшләү буенча урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов, «Әлфия Афзалова иҗатын саклау һәм үстерү фонды» президенты Зөлфия Нигъмәтҗанова-Афзалова һәм башкалар бар иде.

Ифтар программасы рәсем ясау, кул эшләре һәм химия тәҗрибәсе буенча күңел ачу мастер-классларыннан башланды. Чакырылган «Бәхет ачкычы» үзәге осталары балаларны брошка ясау сәнгатенә өйрәттеләр, ә бу вакытта башка балалар мәчет ясарга өйрәнделәр. Аниматорлар балаларга һава шарлары тараттылар.

«Зәкят» фонды карамагындагы Тимур Фазлыев бәйрәмгә рәсми башлангыч бирде, ул Коръән аятьләрен укыды. Аннары «Зәкят» хәйрия фонды генераль директоры Булат Мәрданов оештыручыларга, иганәчеләргә һәм волонтерларга рәхмәтен белдерде. Ул шулай ук «Зәкят» фонды белән күп еллар хезмәттәшлек итүчеләргә һәм ярдәм күрсәтүчеләргә, бу эшкә битараф булмаучыларга рәхмәт хатлары тапшырды.

Аннары мөфтинең рәсми органнар белән эшләү буенча урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов бәйрәм кунакларына мөрәҗәгать итте. Үз чыгышында ул дини һәм милли мәнфәгатьләргә карамастан, кешеләрнең бердәмлегенең мөһимлеген билгеләп үтте:

– Бүгенге чара безне – рус һәм татарларны, христиан һәм мөселманнарны берләштерде. Аллаһы Тәгалә – Яратучыбыз, без барыбыз да Аңа кайтачакбыз. Тормышыбызда нинди генә хәлләр булмасын, Раббыбыз безгә нинди генә сынаулар җибәрмәсен, без матур сабырлык күрсәтергә тиешбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сүзләрен искә төшерәсем килә: «Ятимнәрнең, авыручыларның һәм мохтаҗларның догалары сәбәпле сез, сәламәт кешеләр, бу дөньяда яшисез». Рамазан ае мөселманнарга гына түгел, барлык якыннарыңа ярдәм итү ае булып тора. Без барыбыз да Адәм галәйһиссәлам балалары».

«Зәкят» фонды үткәргән чараларга берничә ел килгән Кадыйровлар гаиләсе бәйрәмнән алган тәэсирләре белән уртаклашты. Зәһрә Кадыйрова бәйрәмгә ире һәм ике кызы белән килгән:

– Безнең гаиләдә үзенчәлекле бала бар. Кече кызыбызга ДЦП һәм тетрапарез диагнозы куйдылар. Берничә ел инде без бөтен гаиләбез белән «Зәкят» фондына йөрибез, балалар дәресләренә дә һәм әниләр өчен оештырылган ял сәгатьләренә дә килергә тырышабыз. Мондый очрашулар нәтиҗәсендә без ялгыз түгеллегебезне аңлыйбыз. Биредә безнең авыруны аңлап кына калмыйча, һәрвакыт рухи яктан да ярдәм итә торган кешеләр бар. Мин аларга моның өчен бик рәхмәтле».

Очрашу ахырында балаларны һәм әниләрне бүләкләр биреп сөендерделәр һәм чәй өстәле артында сыйладылар.

ТР мөселманнары Диния нәзарәте халыкның социаль яктан яклanмаган бик күп катламнарына ярдәм күрсәтү буенча мөһим башлангычларны актив рәвештә гамәлгә ашыра. Әлеге эшчәнлек мөфтиятнең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан башкарыла. Фондның иң мөһим башлангычларыннан берсе – авыру балаларны дәвалауга матди ярдәм күрсәтү буенча махсус программа. Әлеге программа 2016 елдан бирле эшләп килә. 2018 елда «Зәкят» фонды мәрхәмәтле кешеләр һәм гаммәви мәгълүмат чаралары ярдәмендә 71 баланың тернәкләнү һәм дәвалану курсын, шулай ук 3 сабыйга катлаулы операция бәясен түләү өчен акча җыеп түләде. Фонд канаты астындагы бәләкәчләрнең күпчелеге ДЦПның авыр формаларыннан интегә һәм аз керемле, күпбалалы, тулы булмаган гаиләләрдә тәрбияләнә.

Авыру балаларга ярдәм күрсәтүгә юнәлтелгән тагын бер әһәмиятле проект булып «Үсешләрендә үзенчәлекләре булган балалар һәм аларның әти-әниләре өчен үзәк» проекты тора. Ул Россия Президентының гражданлык җәмгыятен үстерүгә юнәлтелгән грантын файдаланып тормышка ашырыла. Татарстан өчен уникаль саналган әлеге проектның 2017 елның ноябрендә башланган беренче сезоны кысаларында 130 гаилә өчен 500ләп дәрес үткәрелде. Яңа сезонда проект «Хәят» исеме астында эшли башлады һәм үзенә йөрүчеләр санын 250 кешегә кадәр арттырды. Үзенчәлекле балалар һәм аларның әти-әниләре өчен Үзәккә йөрү бушлай.

**dumrt.ru**

# «Рамазан Фест»

## *Гаилә бәйрәменә рәхим итегез!*


Ураза гаете быел Казанда бәйрәм вәгазе белән чикләнмичә, шәһәр халкы катнашында тантаналы чаралар белән билгеләп үтеләчәк. Аның иң зурысы 4 июнь көнне көндезге сәгать 13.00-дә Казанның Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркында узачак. Биредә «Рамазан Фест» дип исемләнгән гаилә бәйрәме оештырылачак. Шәһәркүләм чараны ТР мөселманнары Диния нәзарәте Казанның Вахитов һәм Идел буе районнары мөхтәсибәтләре белән берлектә оештыра.

Бәйрәм программасы гаилә ныклыгы, яшьләр һәм өлкәннәр арасында буыннар чылбырын ныгыту темасына багышлана. Теманы әби, бабай, әти, әни, абый, апа һәм оныклар ролендәге артистлар ачып салачак – алар килгән кунакларны паркның төрле урыннарында эшләячәк мастер-классларга җәлеп итәчәк. Дәресләрдә чигү, бәйләү, күннән беләзекләр, пластилиннан, балчыктан төрле әйберләр ясау, акча сугу, рәсем ясау, баш яулыклары бәйләү, никах күлмәкләре модасын карау планлаштырыла.

Шулай ук бәйрәмдә катнашучыларны төрле мавыктыргыч квестлар, триал, воркаут тамашалары, футбол фристайлы белән куандырачаклар. Аниматорлар аквагрим, сабын куыгы очыру һәм фәнни тамашалар тәкъдим итәчәк. Төп сәхнәдә чараны танылган ди-джей Айрат Заһриев алып барачак. Шулай ук Ильяс Халиков башкаруында мөнәҗәтләр яңгыраячак.

Моннан тыш, бәйрәм кунакларын сыйнигъмәтле табын көтә. Программа күккә шарлар очыру белән тәгәлләнәчәк. Чарада барлыгы 10 мең кеше катнашыр, дип планлаштырыла. Бәйрәм паркка килүчеләрнең барысы өчен дә уздырыла, шуңа мөселман булмаган кунаклар да чарада үзләрен рәхәт хис итәчәк, ди оештыручылар.

# Кәгазьгә яңа тормыш бүләк ит!



ТР мөселманнары Диния нәзарәте макулатура җыю буенча «Кәгазьгә яңа тормыш бүләк ит» республика хәйрия акциясен игълан итә. Макулатура тапшырудан җыелган акча матди ярдәм сыйфатында «Зәкят» хәйрия фонды карамагындагы авыру балаларны дәвалауга юнәлтеләчәк. Узган елларда акциягә казанлылар гына түгел, Татарстан районнарында яшәүчеләр дә күпләп кушылды. Әйтик, 2018 елда барлыгы 11,8 тонна күләмендә макулатура җыелды.

Казанлылар макулатураны **Сара Садыйкова урамы, 6/22нче йорт** (хуҗалык блогы) адресы буенча урнашкан кабул итү пунктына китерә ала. Белешмә өчен телефон: +7939390567. Шалтыратулар эш көннәрендә 10.00нан 16.00га кадәр кабул ителә.

Искәртеп узыйк: Татарстанда авыру балаларга ярдәм йөзеннән «Рамазан – изге гамәлләр ае» акциясе башланды. Сабыйларга ярдәм итү өчен **САДАКА** сүзен язып, **7715** номерына SMS-хәбәр җибәрергә кирәк.

# Квас эчәсем килә... Хәләлме ул?



Әчетелеп ясала торган, гөнаһ белән ассоциациясе булмаган, исерү өчен һәм кулланeasuы гөнаһлы кешеләргә охшар өчен эчелми торган квас, кефир, кумыс һәм шуңа охшаш традицион эчемлекләр (әгәр исертми торган булсалар) эчәргә яраклы булып санала.

■ halalrt.ru

# Алкогольсез сыра хөкеме




Исерткечсез (алкогольсез) сыра хөкеменә килгәндә, ул тыелган. Алкоголе булмаса да, андый сыраны эчүче – алкогольле сыра эчкән гөнаһлы кешегә охшап кала.

Әгәр дә урамнан кулына исерткечсез сыра тоткан бер яшь бала узып барса, моны мөселман булмаган кешеләр дә, мөселманнар да шелтәләр иде. Ә кулында квас булса, мондый хәл булмас.

Исерткечсез сыраның халык күрергә иялэнгән алкогольле сыра һәм, әлбәттә инде, гөнаһ белән ассоциациясе көн кебек ачык тора.

■ halalrt.ru

# Хәләл продукция җитештерү




**– Марат Готыф улы, соңгы арада «Halal life style» дигән төшенчә актульләшә башлады. Татарстан Республикасы буенча алганда, хәләл азык-төлекне экспортлаштыру буенча безнең нинди перспективалар бар?**

– Перспективалар бик зур. Минемчә, без әле бу юлның башында гына торабыз. Безнең Республикабыз бу өлкәдә әйдәп барырга тиеш. Күптән түгел булып узган «Kazan Sammit» кысаларында моңа карата берничә конференция узды. Беренчесе хәләл продукция җитештерү турында булса, икенчесе, гомумән, аларны экспортлаштыру турында иде. Мин, әлбәттә, азыкны әзерләү буенча гына җавап кайтарам, хәләл яшәү рәвеше – ул бит киң кырлы әйбер.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында 72 оешма Россия Федерациясенең аккредитацияләү системасы буенча кирәкле сертификатларга ия. Ә читкә чыгару буенча, ягъни экспорт буенча, сертификат әлегә бер генә оешмада бар.

Югарыда әйтеп узганча, конференциядә түгәрәк өстәлләр бик файдалы булдылар. Ул минем үземә дә, шулай ук минем бу өлкәдә эшли торган командама да кызыклы булды. Без бу эшкә төрле белгечләрне дә чакырдык. Хәзер ТР ТМДНнең «Хәләл» комитеты белән Россия экспорт үзәге берлектә эшлиләр.

Командаларыбыз эшләп килә. Узган елны безнең үсешебез 25%ка артты, әмма безгә күп тапкырга үсәргә кирәк. Әгәр дә бу үрнәкне 2 000 000 татар кешесе яшәп килә торган Татарстан күрсәтмәсә, ил өчен бу үрнәкне кем күрсәтергә тиеш ди? Һәм менә бу очрашулар, төрле компанияләр белән фикер алышулар, әңгәмә корулар, барлык төр тәкъдим һәм таләпләрне өйрәнү – болар барысы да шушы өлкәдә зуррак адымнар белән атларга ярдәм итәчәк.

**– Татарстан Республикасында җитештерелә торган хәләл продукциясе белән чит илләрнең кызыксынуы нинди дәрәҗәдә?**

– Барысы да безне көтәбез диләр, әмма аларга «шакылдата» башласак, алар төрледән-төрле документлар таләп итәләр. Кызганыч, хәтта шул ук гарәп илләрендә дә бер дәүләтнең стандарты икенче дәүләт стандартына туры килми. Нииндидер үзара килешүләр юк. Ягъни, әгәр дә 4 төрле гарәп иленә продукцияләрне кертергә теләсәк, аларның һәрберсендә аерым сертификация үтәргә туры киләчәк. Кулай чыгу ысулы – бердәм һәм универсаль стандартка килү. Бу очракта, чыгу буенча эшләп тә, шулай ук алга таба нәрсә дә булса планлаштырып та була. Моннан тыш шул чит илләрдә партнерлар табу да, логистика да ачык мәсьәлә булып кала бирә. Халыкара сертификат белән әлегә бер генә ширкәт эшләп килә. Әйткәнемчә, перспектива зур, әгәр дә (калган ширкәтләр дә сертификацияле булып), читкә чыгарыла торган продукцияләрнең ассортименты күбрәк булса, экспорт мәсьәләсендә без зуррак уңышларга да ирешә алыр идек.

Алдыбызда зур максат тора – 2024 елга экспортны ике тапкырга арттыру, аны 360 000 000 долларга җиткерү. Һәм хәтта бу икеләтү дә Татарстан өчен кечкенә күрсәткеч, без өчләтә, бишләтә артыграк эшләргә тиешбез.

**– Хәләл продукцияне Татарстан күләмендә һәм чит өлкәләрдә популярлаштыру өчен нинди гамәлләр кылырга кирәк?**

– Укырга кирәк. Менә бу конференциягә килгән башка дәүләт вәкилләре белән аралашып, без бик күп мәгълүмат ала алдык. Аларның һәм, гомумән, хәләл продукцияне экспортлау буенча зур тәҗрибәләре булган компанияләрнең белгечләрен чакырып, үзебездәге хәләл продукцияне экспортлаштырырга әзер булган потенциаль оешма вәкилләрен өйрәтергә кирәк. Шул рәвешле, бу безгә алдагы көннәрдә эшне башлап җибәрү өчен техник яктан да, документларны әзерләү ягыннан да һәм читтә партнерлар табу мәсьәләсендә дә әзер булырга ярдәм итәчәк. Читкә чыгу – ул бер мәсьәлә генә. Үз тарафында синең, әлбәттә, барлык төр документлар әзер, технологияләр, иң мөһиме – сыйфатлы җитештерелгән продукция булырга тиеш. Читкә чыккач, алып килгән продукция көндәшләрнекенә каршы торырлык булырга тиеш бит.

**– Марат Готыфович, әңгәмәгез өчен зур рәхмәт.**

■ «Хозур ТВ»

# 40 вәҗиб гамәл

Вәҗиб гамәлләр дә фарыз кебек шәригатьтә кылырга боерылган гамәлдер. Вәҗиб гамәлне кылган кеше савапլы булыр, гозерсез (сәбәпсез) кылмаган кеше гөнаһлы булыр, вәҗиблегенә ышанмаган кеше имансыз ук булмаса да, зур гөнаһлы булыр. Мөэмин вә мөселман булган кешегә кылуы вәҗиб булган гамәлләрнең мәшһүрләре кырыктыр:

1. Йорт кирәкләреннән артык малы булган кешегә Рамазаннан соң фәкыйрьләргә үзе һәм сабый балалары өчен фитыр садакасы бирү.

2. Йорт кирәгеннән артык малы булган кешегә Корбан гаете булган көннәрдә үзе өчен корбан чалу.

3. Ихрамга кереп, Кәгъбәне тәваф кылып һәм Сафа белән Мәрвә таулары арасында йөреп, гомерендә бер мәртәбә гомрә хаҗын (гомрә хаҗы фарыз булган хаҗдан башкадыр, кайсы айда кылынса да дөрес) кылу.

4. Гает-фитыр вә гает-корбан намазларын уку.

5. Һәр көн ястү намазыннан соң витр намазын уку.

6. Зөлхиҗҗә аенда Гарәфә, гает вә тәшрикъ көннәрендә җәмәгать белән укылган фарыз намазларны укып, сәлам биргәч тә тәкбир-тәшрикъ әйтү.

7. Коръәнне тәҗвид кагыйдәләренә муафыйк итеп, дөресләп уку.

8. Коръәндәге 14 сәҗдә аятьләреннән берсен укыган вә ишеткән кеше сәҗдә-и тиләвәт кылу.

9. Вәгъдә вә гәһед (килешү) кылып әйтелгән эшне үтәү.

10. Аллаһы Тәгаләнең исемен тәгъзыйм белән олылап (Тәгалә, Тәкаддәсә, Вә җәллә шә’нүһү) диеп зекер кылу.

11. Киләчәк заманда бер эш кылуны сөйләгән вакытта «ин шә Аллаһ, кылырмын» дип әйтү.

12. Хатын – иренә, ир – хатынына ягымлы булу.

13. Шәкерт остазын күреп, тәгъзыйм кылу (хөрмәт күрсәтү).

14. Күңел илә һәр кешегә хәер эшләрне вә яхшылыкны теләү.

15. Көче җиткән кадәр адәмне вә хайваннарны һәлакәтлектән коткарырга тырышу.

16. Бирелгән бүләк вә һәдияне кабул итү.

17. Бүләккә каршы бүләк бирү.

18. Үзеңә яхшылык иткән кешегә яхшылык итү.

19. Хәләл тәгамле мәҗлескә чакырган кешенең мәҗлесенә бару.

20. Үзеңнең җәберең тигән кешедән гафу кылып бәхилләвен үтенү.

21. Алучыга сатылачак малыңның гаепләрен сөйләү.

22. Иман әһеленең дөньяда рәхәтлеге вә Ахирәттә изгелеге өчен кулыннан килгән кадәр хезмәт вә ярдәм кылу.

23. Иманлы кешенең эшен мөмкин кадәр яхшылыкка юрау.

24. Мосафир кешегә өйлә, икенде вә ястү кеби намазларда дүрт рәкәгать фарызларны ике рәкәгать итеп кыскартып уку.

25. Бер мәҗлестә бер кешегә кылмаган гаепне кылды дип бөһтан (нахак) вә ифтира (яла ягу) кылынса, белгән кеше хаклык илә ул кешенең гаебе юклыгын сөйләп, аны яклау.

26. Ачу килгән кешегә, дин вә гыйбадәтенә зарар килмәслек булганда, өч көн тулгач, тышкы кыяфәттән булса да, үпкәне бетерү.

27. Муафыйк (лаеклы) кеше сораганда, үзенең ризалыгы белән кыз баланы кияүгә бирү.

28. Ихрамлы кешегә харам булган эшне кылган хаҗига тиешле корбан вә тиешле җәзасын үтәү.

29. Күркәм холыклар белән холыклану.

30. Һәр нәрсәгә гыйбрәт күзе белән карап, гыйбрәтләнеп, холыкны төзәтү.

31. Казый вә түрә булган кешегә мазлумнарның шикаятен (гозерен) тыңлап, тугры хөкем кылу.

32. Галим булган кешегә белер өчен соралган мәсьәләгә җавап бирү.

33. Казага калган намаз вә рузалары өчен үзе вафат булганчы, варисларына фидия садакасы бирү илә васыять әйтү.

34. Үзе вафат булганчы, калачак малдан вакытында бирелми калган зәкят гошерләрен үтәү илә варисларына васыять әйтү.

35. Өстенә хаҗ фарыз булып та, вакытында кыла алмаган кеше, варисларына калган малдан бәдел хаҗы кылдыру илә үзе вафат булганчы васыять әйтү.

36. Варис булган кешеләр калган малның өч өлештән бер өлеше кадәресе белән мәетнең әйтеп калдырган васыятьләрен үтәү.

37. Ата-анага балаларына дин, гыйбадәт вә әдәпне өйрәтү.

38. Мөхтәрәм кардәш вә туганнар бер-берсенә дуслык кылышу.

39. Ике хатыны булган кеше хатыннарына тәрбиядә вә нәүбәтләрендә тигезлек вә гаделлек кылу.

40. Һәр гыйбадәттә вәҗиб булган гамәлләрне үтәү. Мәсәлән: намазда – 22 вәҗиб, хаҗда – 5 вәҗиб, гомрәдә – 2 вәҗиб бардыр.

■ **Ә. Максудиның «Шәригать хөкемнәре» китабыннан**

# Фидия

Рамазан аенда ураза тота алмаган кешеләр уразаларын башка айларда тота ала, ә уразаны бөтенләй тота алмаган бик олы яшьтәге кешеләр һәм ураза тотарлык хәле булмаган озак авырган кешеләр уразаның төшереп калдырылган һәр көне өчен фидия садакасы түләргә тиеш була. Фидия – ураза тотмаган көннәр өчен бирелә торган садака. Фидия акчалата түләнергә мөмкин.

Фидиянең күләме нәкъ фитыр садакасы шикелле хисаплана. Фидияне Рамазан аеның башында да, уртасында һәм ахырында да бирергә була.

Фидияне үзең теләгәнчә бер генә фәкыйрь кешегә бирергә яисә берничә кешегә таратырга да мөмкин.



Әгәр мөселман кешенең фидия өләшергә көченнән килми икән, ул вакытта Аллаһыдан гафу үтенергә тиеш.

Әгәр озак авырган кеше инде тазарса, яисә карт кешегә уразасын тотарлык көч-хәл керсә, алар калдырган көннәре өчен уразаны каза итеп тотарга бурычлы. Әлеге очракта бирелгән фидияләре садака булып санала.

Казага калып та, соңыннан үтәлмәгән уразалары булган кешегә, үзеннән калачак малыннан (тотылмаган уразалары өчен) фидия бирергә варисларына әйтү – вәҗиб.

Әгәр шундый васыять әйткән кеше вафат булса, калган малының өчтән бер өлешен, каза кылынмый калган уразалары өчен дип, фидия итеп бирү варисларына вәҗиб була.

Вакытында тоткан уразалар, укылган намазлар, соңыннан каза кылынган уразалар һәм намазлар өчен фидия бирелми.

■ **«Ислам дине нигезләре» китабыннан**

# Фитыр садакасы

Бәйрәм көне җиткәндә бурычлары булмаган һәм нисабка ия булган мөселман кеше өчен фитыр садакасын бирү вәҗиб булып санала. Фитыр садакасы бирер өчен мал-мөлкәткә тулы ел буе хуҗа булырга яки арта барган мал-мөлкәт булырга тиеш дигән шарт куелмый.

Фитыр садакасын Рамазан аенда өләшәләр, моның өчен иң хәерле вакыт – Рамазан гаете көнендә таң атканнан соң Гает намазы укылганчы бирү, чөнки бәйрәмне тояр өчен акчасы булмаган фәкыйрьләрне бәйрәм башланганчы шатландыру хәерлерәк. Фитыр садакасын Рамазан ае барышында ук биреп куярга да мөмкин. Гает укылганчы бирә алмый калган кеше соңыннан бирергә тиеш була. Хәлле мөселман өчен фитыр садакасын үзе өчен дә, балигъ булган балалары өчен дә бирү вәҗиб. Гадәттә фитыр садакасы итеп түбәндәге азык-төлек төрләренең берәрсе билгеле бер күләмдә бирелә:

1. Бодай – 1,6 кг.
2. Солы – 3,2 кг.
3. Йөзем – 3,2 кг.
4. Хөрмә – 3,2 кг.

Фитыр садакасын азык-төлек белән дә, шуның бәясе кадәр итеп акчалата да бирергә була. Мохтаҗ кешегә күбрәк файда китерә торган нәрсәне садака итеп бирсәң хәерлерәк. Фитыр садакасы бүлеп өләшенми, күләме зур булмавы сәбәпле, аны бары тик бер кешегә бирәләр. Бер фәкыйрьгә бердән артык фитыр садакасы бирергә була. Фитыр садакасын биргәндә аның бирүең турында ният ителә һәм ишетелерлек итеп әйтү шарт түгел.

Нисаб микъдарында малмөлкәте яки акчасы булган һәм Рамазан аенда ураза тотмаган кеше шулай ук фитыр садакасы бирергә тиеш була.

Бәйрәм көнендә фитыр садакасы таратып, бай мөселманнар фәкыйрьләрне сөендерә. Фитыр садакасын бирү, мөэминнең тоткан уразасы кабул ителүгә сәбәп була, аны газаплы үлемнән һәм кабер газабыннан коткара.

■ **«Ислам дине нигезләре» китабыннан**

# Рамазан аеннан соң да гыйбадәтләрне киметмәгез

Рамазан ае тәмамланып килә. Ул – безнең Аллаһы Тәгаләгә ихлас гыйбадәт һәм гамәлләр кылуга өметләнгән, изге ниятләр белән көткән мөбарәк аебыз. Бу вакытта һәркайсыбыз үз алдына төрле максатлар куйды: һәр көн Коръәни Кәримне уку, аны дөрес итеп тулаем укып чыгу, нәфел намазларын арттыру, изге эшләрне күбрәк кылу, үз-үзебезне даими катгый тәртиптә тоту… Без кайбер максатларыбызга ирештек, ә нәрсәләрдер әле авыр булып, эшләнелми калды.

Аллаһы Тәгалә безгә күп төрле рәхмәтләрен ирештереп тора. Шуларның иң зурлары – ул гыйбадәт. Рамазан аендагы ураза – иң зур гыйбадәт. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Ий мөэминнәр! Сездән әүвәлгеләргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә һәр елны бер ай ураза тоту фарыз ителде, шаять, уразаны калдырудан яки аңа кимчелек китерүдән сакланырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Белгәнебезчә, Рамазан аенда кеше үз нәфесе белән көрәшә, шайтаннар богаулана. Һәм шушы айда ихласлылык арта. Мәчет юлын бер тапкыр да таптамаган кешеләр мәчетләргә киләләр. Фарыз намазларын, тәравих намазларны укып, уразалар тоталар һәм шушы халәт ай буе дәвам итә, чөнки кешенең җаны Аллаһының рәхмәтенә бик сусаган була. Әмма Рамазан ае бетү белән, бу ләззәт тә бетә, янә гади тормыш башлана. Тик мөселман кешесе шушы изге айда алган тәкъвалык дәрәҗәсен югалтмаска тиеш. Аз-азлап, ләкин дәвамлы булсын. Аз булса да, әмма дәвамлы булган эш нәтиҗәсен китерә. Бу хакта сөекле Пәйгамбәребез болай дип әйткән: «Ураза тотуның кабул ителү билгесе – ул мөселманнарның башка вакытта да ел буенча, Рамазан аендагы кебек, гыйбадәттә булуыдыр».

Димәк, Рамазан ае тәмамлангач та, безгә гыйбадәтне туктатмый, бер дәрәҗәдән икенчесенә үстерергә кирәк. Ихласлыгыбызның Рамазан аеннан башка да югары дәрәҗәгә ирешүенә ничек ирешергә, нинди гамәлләр кылырга соң? Менә аларның кайберләренә тукталып үтик:

### 1. Ният

Безнең һәр кылган эшебез, барлык гыйбадәтләребез дә Аллаһының ризалыгы өчен булырга тиеш. Шуңа да һәрбер хәрәкәтебезне, һәр гамәлебезне Аллаһының олуг исеме «Бисмилләһ» белән башлыйк.

### 2. Намаз

Тиешле булган биш вакыт намазларыбызны вакытында үтәргә тырышыйк. Шулай ук сөннәт һәм нәфел намазлар турында да онытмыйк.

### 3. Коръән уку

Рамазанда иң зур игътибар бирелә торган гыйбадәт – ул Коръәни Кәрим. Коръән һәр мөселман өчен иң мөһим китап. Аның Рамазан ае белән бәйләнеше бик нык, чөнки ул нәкъ менә шушы айда иңдерелде. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм тау куышында булган вакытында, Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам килеп: «Укы», – дип әйтә. Шушы мизгелдән дөньялыктагы иң олы китапларның берсе – Коръән иңә башлый. Шул рәвешле, дөньяга Аллаһы Тәгаләнең соңгы рәхмәте иңә. Шушы китапны бүгенге көнгә кадәр ничә миллионлаган кеше укый, ятлый. Мөгаен, Коръән ул җир йөзендә иң күп укыла һәм ятлана торган китаптыр.

«Һәр көнне Коръәннән 10 бит яисә 1 җөз укыйм», – дип үз алдыгызга башкарып чыга алмаслык максатлар куймагыз. Укылган Коръән битләренең саны артыннан кумагыз, ул көненә 3 аять булырга да мөмкин, ләкин сез ул аятьләрне ихлас тырышлык белән, күңелләрегезгә сеңдереп укысагыз, тәфсир ярдәмендә үзегезгә мәгънәсен ачыкласагыз, уйланып, тәмам төшенеп, тормышыгызда һәм гамәлләрегездә куллансагыз, яхшы булыр. «Уйлапфикерләп үткәргән төннең бер сәгате намаз өстендә торган төннән хәерлерәк», – дип әйтелгән хәдисләрдә.

Мөслим җыентыгында мондый бер хәдис бәян ителә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә Коръән аны укыган кешеләргә шәфәгать итәр». Шулай ук Тирмизи риваятендә китерелә: Кыямәт көнендә Коръән килер һәм: «Йә Раббым, Коръән укучыны бизә», – дип әйтер. Шушы адәмнең башына таҗ кидертерләр. Шуннан соң Коръән әйтер: «Йә Раббым, өстә аңа». Һәм аңа кадерле кием кидертерләр. Бераздан Коръән янә әйтер: «Йә Раббым! Разый бул аннан». Һәм аннан разый булырлар. Коръән укучыга әйтерләр: «Укы һәм күтәрел». Һәр укылган аять өчен аңа әҗер-савап өстәрләр. Әнә шундый эчәлектәге хәдисләр шактый. Тагын нинди гамәлләр өчен шушындый дәрәҗәләргә ирешеп була? Коръән яңгыраган җирдә һәрвакыт нур булыр. Кайбер кешеләр Коръәнне укый белсәләр дә, аның мәгънәсенә төшенмәскә мөмкиннәр. Әмма аларга да Аллаһы Тәгалә Үз рәхмәте белән әҗерләрен насыйп кылыр. Ә кемдер төртелә-төртелә, авырлык белән укырга мөмкин. Хәдистә әйтелгәнчә, аның өчен дә әҗер булыр. Хәдистә китерелә: «Кем Коръәнне шома итеп, җиренә җиткереп укый, ул иң бөек дәрәҗәдәгеләр белән булыр. Ә кем инде аны төртелә-төртелә укый, укырга өйрәнә, аңа икеләтә әҗер булыр».

«Коръәнне тавыш белән укучы ачык садака бирүчегә тиң, ә Коръәнне эчтән укучы, садаканы яшерен рәвештә бирүчегә тиң» (Имам Әхмәд җыентыгыннан).

Коръәнне укыганнарын ишеткән очракта, шулай ук тынлык сакларга кирәк. Аллаһы Тәгалә Үз китабында болай дип әйтә:

**«Коръән укылганда яки Коръәннән вәгазь сөйләнгәндә ихлас тыңлагыз, сүз сөйләмичә, эш эшләмичә тик торыгыз! Шулай итсәгез, шаять, рәхмәт кылынырсыз».**

«Әгъраф / Пәрдә», 7:204

Бу әҗер-саваплар һәммәсе Коръәнне укыган, ятлаган, өйрәткән өчен бирелә. Аллаһы Тәгалә каршында Коръәнне хөрмәтләп яшәгән, ятлаган кешеләрнең дәрәҗәсе шундый зур.

### 4. Догада булу

Аллаһыга даими дога кылуда булырга кирәк. Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай дип әйтә:

**«Сезнең Раббыгыз әйткән: «Сорагыз Миннән һәм Мин сезгә җавап бирермен. Дөреслектә, Миңа гыйбадәт кылудан өстен булганнар җәһәннәмгә кимсетелгән рәвештә кертелерләр».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:60

### 5. Белем эстәү

Күпләребез изге Рамазан аенда гыйлемнәрен арттырдылар – Коръәннән яңа аятьләр өйрәнелде, яңа китаплар укылды, яңа хәдисләр белән танышып, вәгазьләр тыңланылды. Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу гамәлләребезне дәвамлы кылыйк, ирешкән үрләрдә тукталмыйк.

### 6. Нәфел уразалар

Шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тоту хәерле икәнен күпләребез белә. Әбү Әюб Әл-Әнсари радыяллаһу ганһе риваять итә: «Аллаһының Расүле галәйһиссәлам болай дип әйткән: «Кем Рамазан аенда һәм шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, гомере буе ураза тоткан кебек булыр». Моңа өстәп, булдыра алган хәтле, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам айларының беренче атнасы көннәрендә һәм яңа туган һәр айның беренче өч көнендә, 13, 14, һәм 15 көннәрендә ураза тотарга мөмкин.

### 7. Юмартлык

Әгәр без Рамазан аенда саранланмасак, садакалар бирсәк, малларыбызны Аллаһы юлында сарыф итсәк, башка вакытларда да шул изге максатны онытмыйк.

### 8. Кардәшлек

Изге Рамазан аенда без барыбыз да вакытыбызны күбрәк дин кардәшләребез арасында уздырдык, бергәләшеп тәравих, җомга намазларын укыдык, ифтарларга йөрештек. Инде Рамазан үткәч тә, ишекләребез ябылмасын, дускардәшлек җепләре өзелмәсен иде.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Без һәрвакыт күңелләребезгә иманыбызның һәм гыйбадәтнең татлылыгын искәртеп торырга тиешбез. Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап, алда санап үтелгән гамәлләрне һәрдаим башкарырга тырышыйк. Киләсе Рамазанга никадәр үзгәрүебезне, башка кеше булуыбызны күрербез: ихласлыгыбыз да көчлерәк, йөрәкләребез дә пакь булыр, ин шә Аллаһ.

**«Раббыбыз! Туры юлга кергән безнең йөрәкләребезне ялгышларга авышулардан сакла, безгә Үзеңнең рәхим-рәхмәтләреңне бир, дөреслектә, Син – Бирүче!»**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:8

■ **Алмаз хәзрәт Галимҗанов, Саба мөхтәсибенең яшьләр эшләре буенча ярдәмчесе, Сатыш авылы имам-хатыйбы**

## Яңа йортка Коръән укыту



**Без яңа йортка күченергә җыенабыз. Ислам дине буенча безгә берәр төрле эш башкарырга кирәкме?**

**Җавап:** Гореф-гадәт буенча яңа фатир яисә йорт сатып алгач, анда күченгәннән соң Коръән ашы уздыралар, анда имамны да чакыралар. Мәҗлес азан әйтүдән башлана, котлаулар һәм вәгазь белән дәвам итә. Вәгазьдә имам Аллаһы Тәгаләнең кешегә нинди зур нигъмәтләр бирүе өчен шөкер итәргә кирәклекне искә төшерә. Аннан соң Коръән укыла («Йәсин» яки «Рахмән» сүрәләре), имам Аллаһыдан яңа торак хуҗаларына мал-мөлкәт, иркен тормыш, сәламәтлек һәм бәхет сорый. Чәй эчкәннән соң гадәттәгечә дога кылына.

## Нәфел уразалар тоту ярамаган көннәр



**Тиздән Рамазан ае тәмамланачак. Ә ураза тоту гадәте бу айдан соң әле бик озакка җитәр дип уйлыйсы килә. Ислам динендә ураза тотарга киңәш ителмәгән көннәр бар, дип ишеттем. Шулар турында сөйләп китсәгез иде.**

**Җавап:** Шәригатьтә нәфел уразасын тоту тыелган яисә мәкруһ булган көннәр бар. Тулырак алар турында мәхәллә имамыннан да сорашырга кирәк булачак. Ураза тоту түбәндәге көннәрдә тыела:

1. Ураза бәйрәме көнендә;
2. Корбан бәйрәме һәм тәшрик көннәрендә;
3. Хатын-кызга иренең рөхсәтеннән башка теләсә-нинди көндә;
4. Аерым җомга көнне генә;
5. Аерым шимбә көнне генә;
6. Шикле көндә (әгәр дә шәгъбан ае тәмамланганнан соң Рамазан ае башланганмы-юкмы икәнлеге билгеле булмаса, ул көн шикле дип атала).

## Зиратка кергәч укыла торган дога



**Яз һәм җәй айларында авылга кайтып, вафат булган туганнарыбызның каберләрен чистарту гадәте бар. Зиратка керүнең берәр төрле кагыйдәләре бармы? Анда кергәч, нинди дога укырга кирәк?**

**Җавап:** Зиратка килгәч, гадәттә, анда күмелгән мөселманнарны болай сәламлиләр:

السَّلَامُ عَلَيْكُمْ أَهْلَ الدِّيَارِ مِنْ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُسْلِمِينَ
وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللَّهُ بِكُمْ لَاحِقُونَ أَنْتُمْ لَنَا فَرَطٌ وَنَحْنُ
لَكُمْ تَبَعٌ نَسْأَلُ اللَّهَ الْعَافِيَةَ لَنَا وَلَكُمْ

**Әссәләәмү галәйкүм, әһләд-дийәәри минәл-мүэминииинә вәл-мүслимииин. Вә иннә ин шәә Аллаһү бикүм ләәхикуун. Әнтүм ләнәә фәратун вә нәхнү ләкүм тәбәгун, нәс-әлүллааһәл гаафийәтә ләнәә вә ләкүм.**

**Мәгънәсе: «Әй, бу йортларның әһелләре, сезгә Аллаһы Тәгаләнең сәламе булсын. Аллаһы Тәгалә дөньядан үткән сезләргә дә вә сездән калган безләргә дә рәхмәт кылсын. Сез бездән әүвәлге кешеләрсез, без сездән соң килгән кешеләрбез. Ин шә Аллаһ, әлбәттә, сезгә тоташырбыз…»**

Ибне Габбас тапшырган хәдистә болай диелә: «Әгәр бер мөселман үзе белгән мөселман туганы кабере яныннан узып бара һәм аны сәламли икән, вафат булган кеше аны таный һәм аның сәламенә җавап бирә».

Кабер янында булганда исерткеч эчемлекләр куллану, шәмнәр, чәчкә бәйләмнәре кую һ.б. рөхсәт ителми. Алар мөселман гореф-гадәтләренә каршы килеп кенә калмый, шәригать тарафыннан бөтенләй тыелган.

■ **Җаваплар Р. Әдһәмовның «Дингә өндәү нигезләре һәм имамның вазифалары» китабыннан алынды.**

## Бер еллык ураза



**Ялгышмасам, ниндидер айда ураза тотсаң, бер ел ураза тоткан кадәр савап алырсыз, дип ишеттем. Ул нинди ай?**

**Җавап:** Ул ай – Шәүвәл ае. Бу айның 6 көнендә ураза тоту бик хәерле гамәл.

Әбү Әюб Әл-Әнсари радыяллаһу ганһе риваять итә: «Аллаһының Расүле галәйһиссәлам: «Кем Рамазан аенда һәм шәүвәл аеның 6 көнендә ураза тотса, ел буе ураза тоткан кебек булыр», – дип әйткән».

Моңа өстәп, булдыра алган хәтле, дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә, зөлхиҗҗә һәм мөхәррам айларының беренче атнасы көннәрендә һәм яңа туган һәр айның беренче өч көнендә, 13, 14, һәм 15 көннәрендә ураза тотарга мөмкин.

## Намазда ялгышу



**Намаз укучы намазда ялгышса нишләргә тиеш?**

**Җавап:** Намаз укучы намазда ялгышса, ягъни:

– намазда булган әркәннәрнең берсен арттырса;
– ике мәртәбә рөкүгъ кылса;
– берәр рәкәгатен арттырса;
– «Фәтихә» сүрәсен калдырса;
– соңыннан укый торган сүрәләрне калдырса;
– «Әт-тәхиятне» калдырса;
– витрда «Кунут» догасын калдырса;
– имам ишеттереп укый торган намазларда эчтән генә укыса;
– эчтән укый торган намазларны тавыш белән укыса, ахыргы тәшәһһүдтән соң сәлам биреп, ике сәҗдә кылыр. Бу сәҗдә – «сәҗдә-и сәһү» дип атала. Аннан соң тәшәһһүд, «Салават» һәм дога укып сәлам бирер.

■ **Мөхәммәд Гашыйк Иләһи Әл-Бәрнинең «Әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан**

# Казанда VII Республикакүләм ифтар узды

Рамазан аеның 20 нче көнендә, 2019 елның 25 маенда Казанда VII Республикакүләм ифтар узды. Россиядәге иң зур авыз ачу мәҗлесләреннән саналган чараны, дөньякүләм спорт вакыйгалары уздырылу сәбәпле ике елллык «тәнәфестән» соң, быел янә «Казан-Арена» стадионы кабул итте. Ифтарны оештыручылар составы үзгәрешсез калды: Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, «Казан-Арена» акционерлык җәмгыяте һәм РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе.

Быелгы ифтарның төп үзенчәлеге катнашучыларның рекордлы санда булуыннан гыйбарәт булды: авыз ачу өстәле һәм грандиоз «намазлык» футбол кырында 15 мең кешегә әзерләнде. Шулай итеп, ифтарда төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр, иҗтимагый һәм дини оешмалар вәкилләре, Иран, Төркия һәм Казахстанның Казандагы илчеләре һәм генераль консуллары, шулай ук күп балалы һәм аз керемле гаиләләр, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һәм башкалар катнашты. Моннан тыш, әлеге чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов булды. Ул әлеге чарага үзенең улы Искәндәр белән килгән иде.

Ифтар, гадәттәгечә, Яшел Үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит хәзрәт Зиннәтуллинның Коръән укуы һәм Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның дога кылуы белән башланды. Аннары республикакүләм мәҗлестә катнашучыларга сәламләү сүзе белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөрәҗәгать итте:

– Һиҗрәттән соң бер ел ярым вакыт узгач, шәгъбан аеның 10 нчы көнендә Аллаһы Тәгалә мондый аять индерә:

**«Ий, иман китерүчеләр! Сездән алдагы кавемнәргә ураза тоту фарыз ителгән кебек, сезгә дә ураза тоту фарыз булды, бәлки, сез тәкъвалылардан булырсыз!»** («Бәкара» сүрәсе, 183 нче аять).

Шулай ук бер хәдистә Пәйгамбәребез Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) болай дигән: «Аллаһы Тәгалә: «Уразадан башка, барлык гамәлләрегезне үзегез өчен кыласыз. Уразаны исә Минем ризалыгым өчен тотасыз. Һәм Мин ураза өчен махсус савап бирермен», – дип әйткән». Ягъни ураза өчен аерым, башка әҗерләр бирелә, ә Рамазан аенда һәрбер изге гамәлебез күпкә тапкырлана.

Рамазан һәм изге гамәлләр турында вәгазь белән шулай ук республикабызның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм ТР мөфтие урынбасары Илфар хәзрәт Хәсәнов чыгыш ясады. Татарстанның танылган дин әһелләренең вәгазьләре «Нашидул-Ислам» төркеме солистлары, шулай ук Ильяс Халиков һәм Ильяс Минһаҗев башкаруында мөнәҗәтләр белән аралашып барды.

Моннан тыш, ифтар кунаклары ураза темасына интерактив викторинада катнашу һәм ТР Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йортыннан бүләкләр алу мөмкинлегенә ия булды.

Чараның иң күркәм мизгелләренең берсе булып халыкның берьюлы һәм бергәләшеп өч авыру бала исеменә 7715 кыска номерына смс белән садака җибәрү торды. Билгеле булганча, Татарстанда Рамазанның беренче көненнән үк Диния Нәзарәте тарафыннан мохтаҗларга ярдәм күрсәтү йөзеннән «Рамазан – изге гамәлләр ае» дип исемләнгән хәйрия акциясе игълан ителде.

Кояш баю вакыты җитү белән, нәкъ 20.05 сәгатьтә ифтарның кульминациясе җитте – кичәдә катнашучылар Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә ахшам намазы укыды. Массакүләм намазны кардәшләребез ачык һавада футбол кырында башкарды. Җәмәгать белән намаз укып, Татарстан мөселманнары бергәләшеп Изге Рамазан аеның соңгы иң мөбарәк көннәрен каршылады. Аллаһы илчесе (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) Рамазан турында болай дип әйтеп калдырган: «Уразаның беренче ун көне – Аллаһының рәхмәт көннәре, икенче дистәсе – гөнаһлардан пакьләнү көннәре һәм соңгы ун көне – җәһәннәм утыннан котылу дәвере» (быел Рамазан ае 29 көнлек булып килә).

Алга таба барлык кунаклар да әзерләнгән өстәлләр янына узды. Гадәттәгечә, Республика ифтарында төп сый пылау булды. Ураза тотучылар өчен төзелгән меню традицион рәвештә хөрмә, өрек, җиләк-җимешләр, су, сок, пылау, кискән ит, өчпочмак, бөккән, чәк-чәк, кәнфиттән торды. Ашамлыкларны әзерләү өчен 1,5 тонна сыер ите, 1,3 тонна дөге, 1,5 тонна яшелчә, шулай ук 3 тонна җиләк-җимеш, 1,5 тонна кипкән җиләк-җимеш, 600 кг казылык эшләнмәләре, 15 мең чәк-чәк, 1 тонна печенье, шулай ук су һәм башка эчемлекләр сатып алынды. Ризыклар Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаментында әзерләнде. Моннан тыш, билет җитмәгән мөселманнар өчен оештыручылар стадионнан читтә авыз ачу өчен өстәмә 1000 данә ланчбокс әзерләп куйган иде.

Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән аралашу барышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов: «Безнең догалар, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать итүебез – Россиядә тынычлык һәм татулык булсын, илебез ныгысын, Республикабыз чәчәк атсын дигән нияттән. Бүген безнең белән бергә дусларыбыз – төрле конфессияләр вәкилләре. Без барыбыз бергә – көчле Россия хакына бердәм коллектив», – дип ассызыклады.

Журналистлар соравына җавап бирep, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин: «Республика ифтары башкала һәм республика халкына мөселманнар бергә җыелган һәм үзләренең милли лидерлары белән бергә намаз укый ала торган урын кирәк булуын тагын бер кат раслый», – дип билгеләп үтте.

«Без Казанның Җәмигъ мәчете мөселманнарның берләшү урыны булуын телибез, шуңа күрә барлык халыкның да фикерләрен исәпкә алачакбыз. Татар халкының рухына туры килердәй проект эшләп, киләчәктә зур матур мәчет салырга планлаштырабыз», – диде Камил хәзрәт.

Республика ифтарын оештыру турында сөйләгәндә, Камил хәзрәт Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең сүзләрен искә төшерде: «Җиңел булса, без бу эшкә алынмас идек тә». Мөфти чараны үткәрүдә катнашкан эшкуарларга, РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе вәкилләренә, «Казан-Арена» стадионы дирекциясенә, шулай ук волонтерларга рәхмәтен белдерде.

– Без республика ифтарына нәтиҗәләр ясамадык әле, әмма хәзер үк кунакларның канәгать калуларын әйтергә була, барысы да бик яхшы узды! Һава торышы да сынатмады. Бүген 15 мең кеше – Президенттан башлап, бер мәйданда җәмәгать белән намаз укыды һәм авыз ачты. Бу республика өчен зур вакыйга, – диде Камил хәзрәт.

Чара ахырында Татарстан мөселманнары башлыгы традицион рәвештә волонтерлар десанты белән очрашты. Камил хәзрәт барлык координаторларга һәм ихтыярчыларга ихлас рәхмәтен белдерде:

«Пәйгамбәребез (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) бер хәдисендә болай дигән: «Рамазан аенда ураза тотучыны ифтар кылдырган кеше ураза тотучы ирешкән савапларга ия булыр, әмма авыз ачтыру үткәрү белән ураза тотучының савабы һич кимемәс». Бүген сез 15 мең кешене ашаттыгыз. Рамазан аенда һәр изге эшнең 700 һәм аннан да күбрәккә тапкырлануын беләбез. Ә бүген Кадер кичәсе булса, 30 меңгә тапкырланачак! Күз алдыгызга китерегез, гадәти вакытта мондый бүләкләргә лаек булу өчен күпме гомер кирәк булыр иде. Иртәдән кичкә кадәр, ураза тоткан хәлдә, сез Аллаһы ризалыгы өчен шундый олуг гыйбадәт кылдыгыз – меңләгән мөселманнарның уңайлы рәвештә авыз ачуына ярдәм иттегез. Аллаһы Тәгалә сездән разый булсын!»

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, быелгы ифтарны уңышлы үткәрү өчен 1400 волонтер җәлеп ителде. Аның иң өлкәненә 79 яшь иде. Ифтарда катнашу өчен гаризалар 16 яшьтән кабул ителде. Шунысы игътибарга лаек, быел волонтерлар ифтарга әзерлекне 20 майдан ук башлап җибәрде: алар мәҗлесне үткәрү урынын оештырды, өмәләр үткәрде, өстәлләр куйды, келәмнәрне түшәде, азык-төлекне әзерләде, яшелчәләр, җиләк-җимеш һәм кипкән җиләк-җимешләрне юды. Ифтар үткәрү көнендә волонтерларга кунакларны каршы алу, күмәк намаз укуны оештыру, аш-су бирү һәм алга таба җыештыру бурычы йөкләнде. Моннан тыш, физик мөмкинлекләре чикләнгән һәм өлкән яшьтәге кунакларны стадионда каршы алу өчен максималь уңайлы шартларны тәэмин итү өчен, оештыручылар 110 стюард катнашында навигациянең нәтиҗәле системасы өстендә эшләде.

VII Республика ифтарында куркынычсызлык чараларын тәэмин итү өчен стадион территориясендә 30 металлорамка, 4 интроскоп урнаштырылган һәм 30 шәхси сак предприятие вәкилләре, 2 ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү бригадасы һәм Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре эшләде.

Меңләгән мәҗлес кунакларының бер өлеше – республика районнары мөселманнары. Ифтарда аларның саны – 2500 тирәсе. Районнардан делегацияләр Казанның спорт объектына махсус транспорт белән килгән иде. Ифтардан соң халыкны автобуслар белән кайтарып кую да оештырылды.

Исегезгә төшерәбез: әлеге зур чараны ТР мөселманнары Диния нәзарәте, «Казан-Арена» һәм РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе оештырды.

■ dumrt.ru












Фото: president.tatarstan.ru

# Һәр мөселманда булырга тиешле дәфтәр



## Бер кыйсса

Хәсән бине Әбү Синан исемле бер тәбигыйн алтмыш ел дәвамында ятып йокламаган (утырып йоклаган), майлы ризыклар ашамаган һәм сусавын басам дип салкын су эчмәгән.

Вафатыннан соң ул бер кешенең төшенә кергән. Теге кеше Хәсәннән: «Аллаһы Тәгалә сиңа карата нинди булды?» – дип сораган. Хәсән бине Әбү Синан исә: «Раббым Аллаһ миңа карата бик мәрхәмәтле булды. Әмма кайчандыр мин берәүнең энәсен алып торган идем, шуны кире кайтармаганмын. Шул сәбәпле мин хәзер җәннәткә керә алмыйм», – дип җавап кайтара.

## Нәсыйхәт

Кечкенә энә алып торып, аны хуҗасына кайтармаган кешенең хәле шундый булса, башкаларның хакын белә торып, махсус үтәмәүчеләрнең (мәсәлән, бурычка алганын кайтармаучының, саткан-да киметеп сатучының, кеше малын махсус бозучының) хәле нинди булыр соң?

Һәр кеше махсус дәфтәр башлап, шунда үзенең бурычларын һәм аңа кайтарырга тиешле бурычларны язып барырга тиеш. Бу хакта Коръәннең иң озын аятендә – «Бәкара» сүрәсенең 282 нче аятендә әйтелә.

Шулай ук бу дәфтәргә әманәт итеп тапшырылган, ягъни саклап торырга бирелгән әйберләрне дә язып барырга кирәк. Әгәр дә дәфтәрнең хуҗасына берәр нәрсә булса, аның варислары дәфтәрдә теркәлгән бурычларны һәм әйберләрне кайтара алачак.

# Зур гөнаһларның берсе

## Бер кыйсса

Берзаман хәзрәти Гомәр урамнан узып барганда, бер өйдә Коръән аятьләрен укып утырганнар. Гомәр радыяллаһу ганһе: **«Дөреслектә, Раббыңның газабы әлбәттә булачак. Бу газапны кире җибәрүче һич юктыр»**, – дигән аятьләрне («Тур тавы» сүрәсе, 7-8 аятьләр) ишетә. Аларны ишетүгә ул, һушын югалтып, атыннан егыла. Кешеләр аны кулларына күтәреп өенә алып кайта. Гомәр радыяллаһу ганһе озак вакыт авырый, кешеләр аның хәлен белешеп торалар.

## Нәсыйхәт

Коръән һәм дин турындагы башка китапларны билдән түбән тотарга ярамый, алар куелган урыннан югарырак утырырга һәм алар торган якка таба аякларны сузып утырырга, ятарга кирәкми.

Аятьләр яки хәдисләр язылган кәгазь кисәкләрен җиргә ташларга ярамый. Мондый кәгазьләрне күрсәгез, күтәрергә кирәк. Безнең ата-бабаларыбыз һәрвакыт шулай эшләгән.

Борынгы бабаларыбыз, кагәзьне шул кадәр хөрмәт иткән ки, хәтта җирдә кечкенә кагәз кисәге күрсә, аларны күтәреп, чистартып, югарырак урынга куя торган булган.

Коръән аятьләре яки хәдисләр язылган кагазьләрне, иске китапларны яндырырга яки чиста урында күмәргә кирәк. Әмма чүп савыта ташларга һич ярамый!

Хәзрәти Гомәр «Аллаһы Тәгаләдән курык!» сүзләрен ишетсә, шундук: «Аллаһыдан курыкмаска Гомәр кем булган», – дип сәҗдәгә ава торган булган.

«Аллаһы Тәгаләдән курык!» сүзләренә «Син үзеңә кара! Моны миңа син әйтәсеңме?!» – кебек җавап кайтару иң зур гөнаһларның берсе булып тора.

# Үлемең нинди булыр?



## Бер кыйсса

Бер кеше базарда яшелчәләр саткан. Гомере буе ул гыйбадәтләргә җиңел караган, әһәмият бирмәгән.

Үлеме килгәндә янәшәдәгеләре аңа: «Ләә иләһә илләллаһ» дип кабатла», – дигәннәр. Җавап итеп ул: «Бер бәйләме – бер лира, бер бәйләме – бер лира», – дип кабатлаган.

## Нәсыйхәт

Әлеге кыйссадан аңлашылганча, һәркем бу дөньяда ничек яшәсә, шулай үлер, үлеме нинди булса – Кыямәт көнне ул шул дәрәҗәдә кубарылыр. Пәйгамбәребез (саллаллаһу галәйһи вә сәлләм): «Һәр кеше ничек үлсә, шул халәттә кубарылыр», – дип әйткән.

# Ничек тыныч кына намаз кылырга?



## Бер кыйсса

Имам Әбү Хәнифә бик бай кеше булган. Коръәннең «Әгъраф» сүрәсендә килгән: **«Ий Адәм балалары! Һәр сәҗдә кыла торган урында гаурәтләрегезне каплар өчен зиннәтле киемнәрегезне алып киегез»**, – дигән боерыкны үтәр өчен, имам үзенә 1500 дирһәм торган кием сатып алган. Бервакыт Әбү Хәнифә янына бер кеше килеп: «Ий имам, һәр намаз вакытында дөяләрем турында уйлыйм, борчылам. Сез шундый бай була торып, ничек итеп тыныч кына намаз кыласыз?» – дип мөрәҗәгать итә. Имам аңа бик тә хикмәтле җавап кайтара: «Мин дөяләремне йөрәгемә түгел, ә утарга бикләп куям».

## Нәсыйхәт

Әйе, үзен һәм гаиләсен тәэмин итәр өчен кеше һичшиксез эшләргә тиеш. Әмма адәм баласы акчаны яратырга тиеш түгел, фәкать аны кулланырга гына тиешле. Хикмәт ияләре әйткәнчә: «Көймәнең тышындагы су – сәяхәт сәбәбе. Көймәнең эчендәге су – һәлакәт сәбәбе».

Имам Раббани рахимәһуллаһи: «Йөрәктә дөнья малына булган мәхәббәтне бетерү бик авыр. Мөмкин түгел диярлек», – дип әйткән.

Намаз вакытында Аллаһы Тәгалә сине Үз хозурында кабул итә. Шул сәбәпле, намаз вакытында башка әйберләр хакында уйлаудан оялырга кирәк.

Башкаларның нәсыйхәтенә колак салу һәм дәрес ала белү – зур нигъмәттер.

*«Рухуль-Бәйан» китабыннан тәрҗемәләр*

# «Әр-Рәхман» сүрәсендәге кайбер нигъмәтләр

Коръәни Кәримнең 55 нче сүрәсе «Әр-Рәхман»га күзәтү ясавыбызны дәвам итәбез. Рәхимле Зат – Аллаһы Тәгалә – бу сүрәдә Үзенең колларына биргән бик күп нигъмәтләрне искә ала һәм шуннан соң еш кына: «Ий, кеше вә җен, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялган дип саный аласыз?» – дип сорау бирә. Бүгенге мәкаләбездә дә шул нигъмәтләрне өйрәнүне дәвам итәрбез.

## Энҗе-мәрҗәннәр турында



Ислам дине матурлыкка, гүзәллеккә аерым бер игътибар бирә. Сүз энҗеләр-мәрҗәннәр турында. Аларның матурлыгы сәбәпле, ул сүзләр бүгенге көндә кеше исеме буларак та билгеле. Аллаһы Тәгалә ошбу сүрәнең 22 нче аятендә: **«Аларның икесеннән дә энҗе һәм мәрҗән ташлары чыгадыр»,** – дип әйтә. Аларның икесе дә дигәне, узган мәкаләбездә карап киткән ике су агымы. Берсе – ачы, берсе – төче. Озак еллар дәвамында хәтта диңгез, океан галимнәре дә мәрҗәннәрне ачы суда гына табып була, дип уйлаганнар. Әмма Аллаһы Тәгалә әлеге аятьтә икесеннән дә дип китерә. Чыннан да, тора-бара мәрҗәннәрне төче суда да таба башлыйлар. Бу Аллаһы Тәгаләнең бер аяте, ягъни кешеләр өчен Ислам диненең хаклыгы өчен дәлиле булып тора. Шулай ук Аллаһы Тәгалә: **«Вә Ул – Аллаһы, җир өстендә диңгезләрне бар кылды да, файдаланырга сезгә иминлек бирде: ул диңгезләрнең яхшы балыкларын ашар өчен вә аннан энҗе-мәрҗәннәр чыгарып, зиннәтләнер өчен…»** – дип әйтә.

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:14

Бүгенге көндә дә энҗе-мәрҗәннәр бизәнү өлкәсендә бик еш файдаланылалар. Ә Аллаһы Тәгалә аларның табылу юлларын 1400 елдан артык элек инде безнең өчен ачык бәян итеп куйган.

## Корабларның суда йөзүләре

**«Кешеләрне вә малларны йөкләп диңгезләрдә йөри торган тау кеби бөек кораблар Аллаһы Тәгаләнекедер, ягъни Аның кодрәтендәдер».**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:15

Шулай ук энҗе-мәрҗәннәрдән соң диңгезләрнең үзләре турында да әйтеп үтәргә кирәктер. Аллаһы Тәгалә аларны кораблар йөзсен өчен имин кылды. Болар барысы да Нух галәйһиссәлам вакыйгасыннан башланды. Аллаһы Тәгалә аңа шундый зур көймәләр төзү серләрен өйрәтте. Кешелек



исә аны мисал итеп алып, диңгезләрдә йөзеп йөрүне өйрәнде. Һәм, Аллаһыга шөкер, бүгенге көндә дә кешелек дөньясы диңгез-океаннарны бик еш файдалана. Элек паруслы кораблар булса, бүгенге көндә кечкенә генә авыл кадәрле дә корабларны очратырга була. **«Вә корабларның диңгезне ярып йөргәннәрен күрерсез; вә сез мөэминнәр шул кораблар белән Аллаһының юмартлыгыннан дөнья кирәкләрен кәсеп итсәгез, шаять, бу нигъмәтләр өчен Аллаһыга шөкер итәрсез!»**

«Нәхел / Умарта кортлары», 16:14

Һәм алар, Аллаһы Тәгалә әйткән кебек, кешеләрнең үзләрен дә, аларның бик зур күләмдәге йөкләрен дә бер җирдән икенче җиргә күчерергә ярдәм итәләр. Бу исә кешелеккә тормышны алып баруны җиңеләйтә, сәүдәчеләргә яңа илләргә юллар ача.

## Күкләр чиге

**«Ий кеше вә җен таифәсез! Әгәр җир вә күкләр читеннән үтеп китәргә көчегез җитсә, ягъни космос бушлыгына чыгарга, үтегез! Юк, үтә алмассыз, мәгәр күп көч вә күп белем, күп мал белән үтәрсез».**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:33

Аллаһы Тәгалә турында галәмнәрнең Раббысы дип әйтәбез. Без күзебез белән күргән галәмнәр бар. Без күрмәгәннәре дә бар. Төннәрен йолдызларны күрсәк тә, аларга кадәр барып җитү мөмкин хәл түгел шул. Аллаһы Тәгалә күкләргә бертөрле чик куйган дисәк тә була. Ул үзе дә «Көчегез җитсә, үтегез», – ди һәм җавап итеп – «аны күп мал, көч, белем белән генә үтәрсез», – дип әйтә. Шулай ук, бу аять белән Аллаһы Тәгалә кешеләрнең көчсезлегенә дә басым ясаган дип әйтсәк була. Әйткәнебезчә, төннәрен миллионлаган йолдыз күрсәк тә, аларга барып җиту ысулын таба алмадык әле без.

Әйе, Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясына төрле чикләр куйган. Һәм кешелек һәрвакыт күзәтү астында. Ул чикләр менә шундый күк чикләре дә булырга мөмкин, әмма, шулай ук, нинди дә булса гамәлләр чиге, сүзләр чиге һ.б. Аларга карата да игътибарлы булсак иде.

## Ташка да аш белән ат

Татар халкында бик яхшы мәкаль-әйтем бар: «Таш белән атканга– аш белән ат». Әмма, кайчакларда, моның киресен дә күрергә мөмкин. Кайбер кешеләр, аларга карата кылган изгелекнең кадерен




белмиләр, киресенчә, эшләгән изгелеккә карата тискәре бер җавап бирергә мөмкиннәр. Әмма Аллаһы Тәгалә безгә бу дөнья өчен мисал булырлык аять китерә. Аллаһы Тәгалә ошбу сүрәдә:

**«Яхшылыкка каршы җавап яхшылык түгелмени?»**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:60

Ягъни, «чын яхшылыкның җәзасы фәкать җәннәттер». Кем бу дөньяда изге гамәлләр кылып яшәде, Ахирәттә дә изгелек табар, ин шә Аллаһ. Кешеләр дә бер-берләренә кылган изге гамәлләрен онытмаска, аларга карата бары тик изгелек белән генә җавап кайтарырга тиешләр. Шулай ук бервакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шушы аятьне укыгач: «Раббыгызның нәрсә әйткәнен беләсезме (аңладыгызмы)?» – дип сорады. Сәхабәләр: Аллаһы һәм Аның Илчесе яхшырак белә», – дип җавап бирделәр. Шулвакыт Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Ул: Бер Аллаһыны танып яшәгән кешенең җәннәттән кала тагын нинди бүләге булырга мөмкин», – дип җавап кайтарган.

Моның турында Аллаһы Тәгалә Үзе дә «Юныс» сүрәсенең 26 нчы аятендә болай дип әйтә:

«Дөньяда Аллаһыга гыйбадәт кылып, яхшылыкларны кылган кешеләргә Ахирәттә яхшылык, җәннәт нигъмәтләре вә аннан да артыграк – Аллаһы Тәгаләнең дидарын күрү булыр».

«Әр-Рәхман» сүрәсенең ахыргы аятьләрендә Аллаһы Тәгалә шул җәннәттәге бакчаларны да тасвирлап китә:

**«Изге мөэминнәргә оҗмахта бу ике бакчадан башка дәхи ике бакча бардыр… Бу ике бакча яшелдер… Ул ике җәннәттә ургып агучы ике чишмә бардыр… Ул ике бакчада төрле җимешләр хөрмә вә анар агачлары бардыр».**

«Әр-Рәхман / Рәхимле», 55:62-68

Күргәнебезчә, Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясына бу дөньяда гына түгел, Ахирәттә дә бик күп нигъмәтләр әзерләгән. Безгә исә боларны күрә белергә кирәк. Шушы «Әр-Рәхман» сүрәсендәге кайбер нигъмәтләр» дигән мәкаләләр ярдәмендә без аз гына булса да Аллаһы Тәгалә кулланылышка биргән бик күп һәм күркәм бүләкләр, нигъмәтләр барлыгына инанганбыздыр, дип өметләнәм. Аларга шөкер итеп, Аллаһының кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, изгелекләр кылып яшәгән кешегә Аллаһы Тәгалә: «Җавабы җәннәттер», – дип әйтә. Безгә дә шөкер итүчеләр һәм уңышка ирешүчеләр исемлегендә булырга насыйп булса иде.

Мәкаләнең ахырында кабаттан шушы сорауны урнаштырасы килә: «Ий, кеше вә җен, Раббыгызның кайсы нигъмәтләрен ялган дип саный аласыз?»

■ **Сәхифәне Гәбделхәким Фәсхиев әзерләде**

# Пәйгамбәрләр һәм илчеләр – кемнәр алар?

## Кем ул «пәйгамбәр»?

Пәйгамбәр сүзенең гарәп теленә тәрҗемәсе «нәбий» була. Ул үз чиратында «нәбә» ягъни хәбәр дигән сүздән ясалган. Шулай булгач, пәйгамбәр – ул нинди дә булса хәбәр алып килүче дигәнне аңлата. Безнең очракта, пәйгамбәр – Аллаһы Тәгаләнең кануннарын алып килүче, халыкка Аның хәбәрләрен җиткерүче. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: **«Алар бер-берләреннән нәрсә сорашалар? Бөек хәбәр турында».**

«Нәба / Хәбәр», 78:1-2

Бу Коръән аятендәге «хәбәр» сүзе нәбә дигән сүз белән белдерелә дә. Шулай итеп, җир йөзенә ничә генә пәйгамбәр килеп китмәсен, аларның барысына да Аллаһы Тәгаләдән вәхи иңеп, шуларны кешеләргә җиткергәннәр.

Моннан тыш тагын берничә фикер яшәп килә. Мәсәлән, нәбий дип гарәпләр юл күрсәтә торган төрле билгеләрне атый торган булганнар. Пәйгамбәрләр дә кешеләргә туры юлны күрсәткәннәр, аларга үз юнәлешләрен табарга ярдәм иткәннәр. Шулай ук «нәбвә» дигән тамыр «югары булу» дигән мәгънәдә дә очрый. Пәйгамбәрләр, чыннан да, бу дөньяда да, Ахирәттә дә югары дәрәҗәләргә ия кешеләр.

## Кем ул «илче»?

Без пәйгамбәребез Мөхәммәдне икенче төрле Расүлуллаһ дип тә атыйбыз. Илче сүзе гарәп телендә «расүл» буларак яңгырый. Илче сүзе татар телендә дә кулланыла һәм «вәкил, җибәрелгән» кебек мәгънәләргә ия.

Расүлләр дә Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә нинди дә булса бер яңалык, хәбәр алып килгәнгә күрә, илче дип аталганнар. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: **«Шуннан соң без расүлләребезне бер-бер артлы җибәреп тордык».**

«Муэминүн / Мөэминнәр», 23:44

Башкача әйткәндә, Аллаһы Тәгалә аларны да халыкка туры юлны күрсәтүче бер вәкил буларак җибәргән.

## Пәйгамбәр һәм илче аермасы

Әгәр дә телдә берәр сүз кулланылса, димәк, ул калган сүзләрдән аермалы мәгънә йөртә. Шуңа күрә пәйгамбәрләр һәм расүлләр бер дип әйтү хата саналыр иде. Күп кенә галимнәр алар арасындагы аерманы болай аңлаталар.

Беренчедән, Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең түбәндәге хәдисе бар: «Пәйгамбәрләр йөз егерме дүрт мең булган, ә илчеләр – өч йөз дә ун һәм тагын берничә (Имам Әхмәд). Икенчедән, Аллаһы Тәгалә дә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: **«Янә Коръәннән Мусаны сөйлә: ул Аллаһыга гыйбадәттә вә Аңа итагать итүдә бик ихлас булды, вә кешеләргә Ислам динен өйрәтер өчен Аллаһыдан җибәрелгән пәйгамбәр вә илче иде».**

«Мәрьям», 19:51

Шулай итеп, илче – яңа канун (шәригать) белән, ә пәйгамбәр – шул канунны дәлилләүче, куәтләүче буларак килгән кеше.

## Пәйгамбәрләргә ышану

Безне кечкенәдән: «Исламның биш, ә иманның алты баганасы бар. Үзен Исламда дип санаган кеше шул 5 баганага таянырга, ә иманлы да дип санаганы – шул 6 баганага ышанырга тиеш», – дип үстерделәр. Чыннан да, Аллаһының барлыгына, берлегенә шәһадәт китергәч, Аның фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәр-илчеләренә, Ахирәт көненә һәм үлгәннән соң кабат терелүгә ышану – мөэмин-мөселманның чын халәтедер.

## Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләр

Пәйгәмбәрләр бик күп булган. Коръән Кәримдә Адәм галәйһиссәламнән башлап Мөхәммәд галәйһиссәламгә кадәр килеп киткән пәйгамбәрләрнең төгәл саны күрсәтелми, әмма хәдисләрдәге мәгълүматка таянып, 124 меңләп пәйгамбәр җибәрелгән дип әйттек. Ләкин аларның төгәл саны Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм.

Коръәндә 25 пәйгамбәрнең исеме искә алына: Адәм, Нух, Идрис, Ибраһим, Исмәгыйль, Юныс, Муса, Давыт, Зәкәрия, Исхак, Сөләйман, Һуд, Салих, Ягъкуб, Йосыф, Лут, Шөгәеб, Ильяс, Яхья, Әюб, Зөл-Кифел, Һарун, Әл-Йәсәгъ, Гайсә, Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә алардан разый булсын.

## Пәйгамбәрләрнең сыйфатлары

Пәйгамбәрләргә хаклык, фәкать дөресне сөйләү кебек сыйфат хас булган, чөнки алар кешеләргә Аллаһы Сүзен җиткергәннәр һәм ялган сөйләргә, алдаларга аларның хакы юк иде.

Пәйгамбәрләр үткен зиһенле, хикмәтле булды, чөнки пәйгамбәр хакыйкатьне матур итеп җиткерә белергә, үз сүзен ышанычлы, саллы итеп яклый белергә тиеш иде.

Пәйгамбәр булуын дәлилләү өчен, барлык пәйгамбәрләргә могҗиза кылу мөмкинлеге бирелде. Әмма көндәлек тормышта алар гади кешеләр кебек булды: эшләгән, арыган, гаилә корган, балалар тәрбияләгән, авырган, башка кешеләр кебек төрле хис-тойгылар кичергән... Шулай да пәйгамбәрләр – кешеләр арасында гына түгел, барлык мәхлүкъләр арасында да иң яхшы, иң лаеклы затлар булды. Кайбер пәйгамбәрләр турында искә төшереп китик әле.

## Адәм галәйһиссәлам

Кемнең дә булса үрнәгендә эшләргә һәрвакыт җиңелрәк. Әмма Адәм галәйһиссәлам беренче кеше һәм беренче пәйгамбәр дә булган. Аның ничек барлыкка китерелүе, җәннәттән чыгарылуы, балалары тарихы бар кешегә дә мәгълүмдер. Анабыз Хәва радыяллаһу ганһә турында да Ислам динен тотучылар гына түгел, барлык дин әһелләре дә беләдер.

Шуны искәртеп үтәргә кирәк: Адәм галәйһиссәлам – бик гыйлемле зат булган, чөнки гыйлемне аңа турыдан-туры Аллаһы Тәгалә биргән: **«Аллаһы Адәмгә исемнәрнең барчасын өйрәтте дә, фәрештәләргә: «Әгәр дөрес сөйләүчеләрдән булсагыз, Адәм белгән исемнәрне барчасын әйтеп бирегез», – дип әйтте».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:31

Шулай ук, Адәм галәйһиссәламнең җәннәттән чыгарылу тарихы, Һабил белән Кабил язмышы да безнең өчен аерым бер дәрес булып тора. Шәйтан үз эшен беркайчан да онытмый һәм гел сагалап кына тора. Шуны да онытмасак иде.

## Ибраһим галәйһиссәлам

Ибраһим галәйһиссәламнең исемен һәр яңа туган сабый да ишетә, ни өчен – чөнки, исем кушканда «Ибраһим галәйһиссәлам милләтеннән, Мөхәммәд галәйһиссәлам» өммәтеннән дип әйтү гадәтләнгән.

Ибраһим белән безгә таныш бик күп вакыйгалар була: Кәгъбәнең төзелеше, Исмәгыйль галәйһиссәлам вакыйгасы (Корбан чалу гыйбадәте шул чордан башлана), Ибраһим галәйһиссәламнең әтисе белән сөйләшүе (ул бүгенге көндә дә дингә йомшаклык белән чакыруның бер үрнәге булып тора), потларны вату һәм утка ыргытылу h.б. Ибраһим һәм Исмәгыйль галәйһиссәламнәрнең Кәгъбәне төзүләре дә үзе бер олуг вакыйга булганлыктан, бу пәйгамбәрләрне һәрбер мөэмин-мөселман беләдер.

## Йосыф галәйһиссәлам

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрен ишетмәгән кеше юктыр. Борынгы әдәбиятыбызның алтын үрнәкләреннән саналган әлеге кыйсса, чыннан да, Йосыф галәйһиссәламнең тормыш юлын хак рәвештә тасвирлап бирә. Ә аның «маҗаралары» төш күргәннән соң башланганын күбегез хәтерлидер. Ахыр чиктә ул үзе дә төшләрне юрый башлый.

**«Йосыф әтисенә: «Ий, атам, мин тешемдә унбер йолдызның һәм ай белән кояш көлеп миңа сәҗдә кылганнарын күрдем», – дип әйтте».**

«Йосыф», 12:4

Коръәннең 12 нче сүрәсе – «Йосыф» сүрәсе. Аллаһы Тәгалә бу пәйгамбәрнең тарихын безгә Үзенең китабында да китерә. Матурлыгы хушны алырлык бу гүзәл пәйгамбәрнең тарихы белән без дә кызынсынсак иде.

## Мөхәммәд галәйһиссәлам

Мөселманнар Мөхәммәднең пәйгамбәр һәм илче булуына ышана. Аны Аллаһы Тәгалә барлык кешеләргә – гарәпләргә дә, гарәп түгелләргә дә, җеннәргә дә җибәрә. Аннан соң бүтән пәйгамбәр булмаячак иканен дә, һәм ул тапшырган канун Кыямәт көненә кадәр гамәлдә икәнен дә без белергә һәм аңларга тиешбез.

Мөхәммәд галәйһиссәлам – туры юлдан тайпылулар, ялгыш карашлар һәм гөнаһлар хөкем сөргән чорда вәхи иңгән пәйгамбәр. Моннан тыш, пәйгамбәребез Мөхәммәд пәйгамбәр үзе килгәнче кабиләләргә һәм гаилә кланнарына таркалган, һәрвакыт үзара дошманлашып торган гарәпләрне берләштерә һәм бербөтен җәмгыять буларак камилләштерә. Бүгенге көндә дә без Пәйгамбәребезнең кардәшлек турында сөйләгән хәдисләренә таянып, берберебезгә ярдәмләшеп, дус-тату булып яшәргә тиешлебез.

■ Сәхифәне Габделхәким Фәсхиев әзерләде

# БАЛАЛАРГА КАРАТА МӘХӘББӘТ



## Мәрхәмәтле булмаганнар мәрхәмәткә ирешә алмас

Баланың иң якын дусты кем ул? Дөрес, аның әти-әнисе. Үзегезнең яшь чагыгызны, самими күңелле булган вакытыгызны исегезгә төшерегез әле. Нәрсә генә булмасын – йә эти, йә әни янына чаба торган идек бит. Боларны истә тотып, үзебезнең балаларыбыз булгач та, аларга да без әти-әниләребездән күчкән җылыны бирә белергә тиешбез. Элекке чорларда әти-әниләр балаларына карата кырыс булганнар, ниндидер рамкалар куеп тәрбияләгәннәр дигән караш бар. Әмма барлык дөньяга үрнәк булган Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең яшәү рәвеше безгә дә дәрес булып тора. Ә аның тәрбия рәвеше иң камил һәм дөресе бит.

Көннәрдән бер көнне Аллаһының хак хәбибе, мәрхәмәт иясе Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең оныгы Хәсәнне кулына ала һәм аны кочаклый, иркәли, үбә башлый. Шулвакыт аның янына җәһилият вакытында зур дәрәҗәләргә ирешкән Әфрабил Харис исемле кеше килә. Ул четерекле мәсьәләләрне хәл иткәндә чакырыла торган казый була, һәм гадел хөкем итәргә омтылуы белән дан казана. Пәйгамбәрнең оныгын иркәләвен күргәч, ул: «Йә Расүлуллаһ! Йә Мөхәммәд! Минем ун балам бар, ләкин мин аларның берсен дә үпкәнем юк», – дип әйтә. Пәйгамбәр моңа: «Мәрхәмәтле булмаганнар мәрхәмәткә ирешә алмас. Кечкенәләргә карата йомшаклык белән, яратып, олыларга карата хөрмәт белән карамаган кеше бездән булмас», – дип җавап бирә.

## Балаларны ярата белергә кирәк

Ярату бик мөһим нәрсә. Кечкенә балалар моңа аеруча мохтаҗ. Аллаһының илчесе үзенең өммәтен дә һәрвакыт бер-берсен якын итәргә, бер-берсен яратырга чакырган. Ярату һәм мәрхәмәтлек күрсәтү бала тәрбиясенең аерылгысыз бер шарты булып тора.

Бер көнне Аллаһының Илчесе янына бәдәви гарәпләрдән булган бер кеше килә һәм: «Йә Мөхәммәд! Димәк, сез балаларыгызны үбәсез?» – дип сорый. «Әйе, әлбәттә», – дип җавап бирә Расүлуллаһ. Бәдәви аңа: «Без исә беркайчан да үпмибез», – дип әйтә. Пәйгамбәребез: «Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә сезнең йөрәгегезгә аз булса да ярату һәм мәрхәмәт хисен салмаган икән, мин нәрсә эшли алыйм?!» – дип әйтә. Шуңа күрә балаларга карата мәрхәмәтле булырга, аларны яратырга һәм ярата белергә кирәк. Балаларның үзаңнарын үстерүнең иң төп һәм мөһим нигезе булып нәкъ менә ярату хисе тора. Бөтен галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән Аллаһының Илчесе үзенең сәхабәләренә һәм шулай ук безгә дә шул принципны аңлатып калдырган. Без балаларны бик яраткан Пәйгамбәрнең иярүчеләре. Аны үзебезгә үрнәк итеп алганбыз икән, без аның юлыннан барырга, балаларыбызга карата мәрхәмәтле һәм яратучан булырга омтылырга тиешбез.

## Балаларны яратуда Расүлуллаһның үрнәге

Пәйгамбәребез болай дип әйтә торган булган: «Мин еш кына намазымны озаграк итеп укырга ниятләп баса идем, ләкин җәмәгать арасында елаган бала тавышларын ишетсәм, намазымны кыскарта торган булдым».

Расүлуллаһның балаларны яратуы аның көндәлек тормышында бик ачык чагыла иде. Ул аларны иңнәренә утыртып йөрткән, алар белән шаярган һәм уйнаган, үзе башлап сәлам бирә торган булган. Башкаларга Пәйгамбәр: «Баласы булган кеше баласы белән үзе дә бала кебек булсын», – дип киңәш итә торган булган. Бер көнне ул кошын ерткыч хайваннар алып киткән баланың кайгысын уртаклашырга барган. Кайвакыт авырып киткән балаларның хәлен белергә чыгып китә торган булган. Шуңа күрә балалар да аны бик каты ятраткаңнар.

Пәйгамбәребезнең балаларга карата мәхәббәтенә тагын бер мисал булып алдагы вакыйга да тора: бәйрәм көннәренең берсендә кечкенә бер малай бер читтә елап утырган. Пәйгамбәребез аның янына килеп, нигә елаганын сорый. Бу бала: «Минем әтием дә, әнием дә юк», – дип җавап бирә. Аллаһының Илчесе бу баланың башыннан сыйпап: «Әгәр теләсәң, бүгеннән башлап синең әтиең Мөхәммәд, әниең Гайшә, апаң Фатыйма булыр», – дип әйтә. Бала да: «Әлбәттә, Расүлуллаһ, мин моны бик телим», – дип җавап бирә. Һәм Пәйгамәр галәйһиссәлам аны җитәкләп: «Алай булгач, әйдә минем белән», – дип аны алып китә һәм үзенең өенә алып кайтып, аны ашата, шатландыра, иркәләп сөя.

## Күз тимәсен өчен догада булыйк

Балаларыбыз күз алмасыннан да якынрак кешеләр. Без аларны салкыннан саклар өчен җылы киемнәр, авырулардан саклар өчен төрле дарулар алабыз. Әмма дөньяда күз тию дигән әйбер дә бар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Хәсән белән Хөсәенгә күз тимәсен дип мондый дога кылган:

أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ شَيْطَانٍ
وَهَامَّةٍ وَمِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ

Әгүүҙү бикәлимәәтилләәһиттәәммәти мин күлли шәйтаанин вә һәәәммәтин вә мин күлли гәйнин ләәммәһ

«Һәр шәйтаннан, зарарлы әйберләрдән һәм начар күзләрдән Аллаһыга сыенам».

Күз тиюдән бу Коръәни Кәрим аятен дә уку киңәш ителә:

وَإِن يَكَادُ الَّذِينَ كَفَرُوا لَيُزْلِقُونَكَ
بِأَبْصَارِهِمْ لَمَّا سَمِعُوا الذِّكْرَ وَيَقُولُونَ إِنَّهُ
لَمَجْنُونٌ وَمَا هُوَ إِلَّا ذِكْرٌ لِّلْعَالَمِينَ

Вә ий-йәкәәдүлләҙиинә кәфәруу ләйүзликуунәкә биәбсаариһим ләммәә сәмигүҙ-ҙикра вә йәкуулүүнә иннәһүү ләмәҗнүүн. Вә мәә һүә илләә ҙикруль лильгааләмииин

«Чынлап та, шул имансызларның, Коръәнне ишеткән вакытта, сине күзләре белән бәреп егасы килә иде. «Ул, һичшиксез, акылдан язган кеше», – дияләр. Ә Коръән бөтен галәмнәр өчен шәфкатьтән башка бер әйбер дә түгелдер».

«Нун», 68:51-52

## Иминле киләчәк теләсәк – саф нәсел сорыйк

Яшерен түгел: киләчәк безнең балаларыбыз кулында. Әти-әнинең бу дөньядагы иң зур кертеме – балалары. Кеше гаилә корганчы ук Аллаһы Тәгаләдән күркәм гаилә, хәләл җефет, саф нәсел сорарга тиеш. Мондый догага мисал итеп Зәкәрия галәйһиссәламнең Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләдән саф нәсел сорап кылган догасын китереп була:

رَبِّ هَبْ لِى مِنْ لَدُنْكَ ذُرِّيَّةً طَيِّبَةً إِنَّكَ
سَمِيعُ الدُّعَاءِ

Рабби һәб лии мил ләдүңкә зүррийййәтәң тайййибәһ. Иннәкә сәмиигү-дүгәәә-ә

**«Әй, Раббым, рәхмәтеңнән миңа бер бала бир! Шиксез, Син минем догамны ишетәсең».**

«Гыймран гаиләсе», 3:38

## Йөкле хатын укый торган дога

Йөкле хатын тиешле медицина тикшерүләре белән бергә дини вазифаларны да үтәргә тиеш. Мөмкинлек булган саен «Аятел Көрси» һәм «Инширах» сүрәсен укырга кирәк. Алардан соң йөкле хатынның шушы догасы укуы булыр:

اللَّهُمَّ أعْطِنَا صِحَّةً وَعَافِيَةً وَاَوْلَادًا صَالِحًا
وَرِزْقًا وَاسِعًا وَدُعَاءً مَقْبُولًا

Аллаһуммә әгътыйнәә сыйххәтән вә гәәфиййәтән вә әүләәдән саалихән вә ризкан вәәсигән вә дугәән мәкъбүүлә

«Аллаһым, безгә саулык һәм сәламәтлек бир. Хәерле балалар бүләк ит, мул ризык биреп, догамны кабул ит, Аллаһым».

***Киләчәкне алдан кайгыртырга кирәк. Олыгайган көндә таяныр кешеләр – ул балалар һәм оныклар булачак. Шуңа да аларга яхшы тәрбия бирергә, күркәм мөгамәлә күрсәтергә, ә, иң мөһиме, чын күңелдән яратырга кирәк.***

# Пәйгамбәребез яратып ашаган яшелчә

Ә сез кыярның кабаксыманнар яшелчә гаиләсенә караганын, ягъни кабак белән кавынга «туган» булуын белә идегезме?

Күпләребез бик яраткан бу яшелчә кешеләргә инде 6 гасырдан артык билгеле, ул борынгы грекларга һәм римлыларга да таныш була. Әүвәл аны Һиндстанда үстергәннәр, аннан ул Азия һәм Мисырга эләгә һәм бу җирләрдән Византиягә, Европага китертелә. Россиягә ул XV гасырда гына керә. Бүгенге көндә Җир шарында кыяр билгеле булмаган бер генә урын да юктыр.

Кайбер хәдисләрдә хәбәр ителгәнчә, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм кыярны бик тә яраткан. Тирмизи хәдисләр җыентыгында мондый хәдис китерелә: «Расүлуллаһ галәйһиссәлам бик тә кавын, карбыз һәм кыяр яраткан». Әбү Давыд җыентыгындагы хәдистә: «Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм яшь хөрмәләрне кыяр белән ашый иде», – дип хәбәр ителә. Габдуллаһ бине Җәгъфәр исемле сәхабә: «Мин Расүлуллаһ галәйһиссәләмнең яшь хөрмәне кыяр белән ашаганын күрдем», – дип әйткән.

## Сәламәтлеккә файдасы

Кыяр иң аз калорияле яшелчә булып тора, 100 грамм кыярда – 14 калория. Шул сәбәпле, ябыгырга теләүчеләр өчен ул бик кыйммәтле ризык. Кыярда май юк. Ул 95-98% судан гына тора. Шуңа күрә кыярлар кеше организмын бик яхшы чистарта, аннан токсиннарны, авыр металл тозларын, төрле зарарлы матдәләрне чыгара. Химик һәм радиоактив матдәләр белән эшләүчеләргә кыярны күбрәк ашарга киңәш ителә.

Кыяр юан эчәклектә яман шеш авыруын булдырмый калырга да ярдәм итә. Түтәлдән яңа гына өзеп алынган кыяр калий чыганагы да булып тора. Калий кан басымын төшерә. Калийга һәм суга бай булуы аркасында, кыяр сидек кудыру үзлегенә дә ия. Кыяр белән туклану бөерләр эшчәнлеген яхшырта. Составындагы витаминнарга килгәндә, аңарда К витамины күп: 100 грамм кыярда – 17 мкг. Шулай ук кыярда С һәм А витаминнары, В төркеменә караган витаминнар бар. Димәк, кыяр һәм башка яшелчәләрдән ясалган гади генә җәйге салат күпсанлы файдалы матдәләр чыганагы булып тора.



Кыяр ферментлары углеводларны тиз бүлгәли, организмга ит һәм балык ризыкларын тизрәк эшкәртергә ярдәм итә.

Борынгы чорлардан ук, хатын-кызлар кыяр һәм кыяр суын бит һәм тән тиресен яхшырту өчен кулланган. Кыярда В төркеме витаминнары күп, дип әйткән идек, бу исә тәндәге төрле ялкынсыну, тимгел, бетчәләр белән көрәшү чарасы. Кыяр суы вак җыерчыкларны бетерә, ул бар төрле тирегә дә туры килә. Шулай ук кыяр тонәтмәләре чәчләргә дә бик файдалы.

Югарыда санап кителгәннәр яшь кыярларга гына карый. Тозланган һәм маринадланган кыярларны исә күп ашарга киңәш ителми, аларда тоз, серкә һәм тәмләткечләр артык күп, ә файдалы матдәләр инде калмый диярлек.

■ **Islam-today**

# Сөт – Аллаһы Тәгаләнең бер билгесе

Сөт – адәм баласының дөньяга килгәч беренче ризыгы булып тора. Гомумән, хайваннарга да сөт нигездә яңа туган балаларын ашатып үстерер өчен бирелгән.

Кеше иң күп кулланган сөт булып бүгенге көндә сыер сөте тора, «сөт» сүзен әйтүгә, күпләрнең күз алдына да нәкъ сыер сөте килә. Бу эчемлек – кеше өчен алыштыргысыз һәм бик кирәкле ризыкка әверелде.

Сөтнең файдасы турында һәркемнең укыганы, табиблардан ишеткәне бардыр. Шулай ук Ислам динендә дә сөтнең билгеле бер урыны бар.

Изге китабыбыз Коръәндә йорт хайваннарының кешеләргә сөт бирүе Аллаһы Тәгаләнең бер билгесе булуы ассызыклана, әлеге күренеш дөньяның нинди катлаулы һәм хикмәтле икәнен күрсәтә.

**«Вә сезгә хайваннарда да гыйбрәтләр бардыр: кан белән тизәк арасыннан чыккан сөтне сезгә эчерәбез, ул сөт эчүчегә ләззәтледер. Ягъни сыерның ашаган, эчкән нәрсәсе канга, иткә, сөткә, тизәккә вә сидеккә бүленә. Шуны кем эшли ала? Шул эш гакыллы кешегә гыйбрәт түгелме?»**

«Нәхел / Умарта Кортлары», 16:66

Башка бер сүрәдә Җәннәттә бик тә үзенчәлекле сулы һәм сөт елгалары агачак, дип хәбәр ителә:

**«Аллаһыга мөшрик булудан, гөнаһлы эшләрдән һәм бидгать гамәлләрдән сакланучы тәкъва мөэминнәргә вәгъдә ителгән Җәннәтнең сыйфаты будыр: ул Җәннәт бер бакчадыр ки, анда татлы елгалар агадыр, аларның тәмнәре вә төсләре үзгәрмәс, дәхи сөт елгасы бардыр, аның да тәме үзгәрмәс, дәхи эчемлек елгасы бардыр, эчүчеләргә татлыдыр вә бал елгасы бардыр, бик пакьтер, янә һәртөрле җимешләр дә бардыр һәм дә Раббыларының гафуризалыгы бардыр…»**

«Мөхәммәд», 47:15

Хәдисләрдә билгеле булганча, Пәйгамбәребез галәйһиссәлам сөтне бик яраткан, башка эчемлекләрдән өстен күргән. Ибне Габбас: «Бар эчемлекләрдән Расүлуллаһ ныграк сөтне ярата иде», – дип әйткән.

Шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәр болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә берегезне ашатса: «Аллаһуммә, бәрик ләнә фиһи вә-рзукнә хайран минһү» («Аллаһым, безгә моны бәрәкәтле ит һәм аның хәерлесе белән ризыкландыр»), – дип әйтсен. Ә әгәр берәрегезгә сөт эчерсә: «Аллаһуммә, бәрик ләнә фиһи вә зиднә минһү» («Аллаһым, безгә моны бәрәкәтле ит һәм моны арттыр»), – дип әйтсен. Мин сөттән башка ризык һәм эчемлекне алыштыра алырдай бернәрсәне дә белмим».



Кайбер хәдисләрдә сөтнең шифалы вә файдалы булуы ассызыклана: «Сөт эчегез, бармак каштан тир тамчысын сыпырган кебек, сөт тә йөрәктән кызуны бетерә. Сөт умыртка баганасын ныгыта, зиһенне һәм ми эшчәнлеген арттыра, күзләрнең күрүен яхшырта һәм онытучанлыкны бетерә». Янә бер хәдистә: «Сыер сөтен кулланыгыз, ул – дару, ә аның каймагы – шифа…», – диелгән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: «Агудан кала, Аллаһы Тәгалә дәвасы булмаган авыру җибәрми. Шуңа күрә сыер сөтен эчегез, чөнки сыер көтүлектә бар төрле үләннәрдә була», – дип тә әйтә.

Билгеле булганча, Миграҗ вакытында Пәйгамбәребезгә ике төрле касә тәкъдим ителә. Аларның берсендә – шәраб, икенчесендә сөт була. Мөхәммәд галәйһиссәлам сөтне сайлый. Аның бу гамәлен Җәбраил фәрештә хуплап: «Син табигыйны сайладың, әгәр хәмер сайлаган булсаң, синең өммәтең туры юлдан адашыр иде. Сөтне сайлап син (кешенең) табигатен сайладың, һәм синең өммәтең кешенең табигый үзлегенә юнәлтелде», – дип әйткән. Чыннан да сөт, кешенең табигатенә иң якын ризык – ул аны туганнан соң ук куллана башлый.

■ **Islam-today**

# Бай сәүдәгәр һәм ярлы

Бер хатын бай сәүдәгәргә кияүгә чыга. Бу сәүдәгәрнең зур гына шәхси кибете булып, ул анда тукымалар һәм киемнәр сату итү эшен алып барган. Бай булуына да карамастан, ул бик нык саран булган. Бер көнне әлеге бай сәүдәгәр тавык сатып алган һәм хатынына аннан кичке аш әзерләргә кушкан. Хатыны ире кушканча ризык әзерләгән. Шулай кичке ашны ашап утырган вакытта, ишеккә шакыган тавыш ишетелә. Сәүдәгәр ишекне ача, анда бер ярлыны күрә. Бу ярлы ач булганлыктан, сәүдәгәрдән ашарына берәр ризык сорый. Сәүдәгәр исә ярлыга ризык бирми, аңа бик каты кычкырып, аны куып чыгара. Бу ярлы: «Әфәндем, Аллаһы Тәгалә сине кичерсен, әгәр минем тамагым ач булмаса һәм ризыкка мохтаҗ булмасам, мин синең ишегеңне шакымас идем», – дип әйтә.

Ярлының әйткән сүзләрен дә тыңлап тормыйча, бай сәүдәгәр ишекне каты итеп ябып, өенә кереп китә. Янәдән өстәл артына утыргач, хатыны иреннән: «Нигә син ярлы алдында ишегеңне каты итеп яптың? – дип сорый. Ире аңа усал гына болай ди: «Әллә мин берәр нәрсә эшләр дип уйладыңмы?» «Син аңа тавыкның бер өлешен, йә булмаса канатларын бирер идең, аның азрак булса да тамагы туяр иде», – дип әйтә хатыны. Иренең моңа ачуы килеп, хатынына болай ди: «Аңа канат бирергә? Әллә акылдан яздыңмы?» Хатыны аңа: «Алайса... берәр җылы сүз булса да әйтер идең», – дип җавап кайтара.

Бу вакыйгадан соң күпмедер вакыт үтә. Шулай бер көнне бай сәүдәгәр үз кибетенә килсә, ни күрсен, кибете янган. Барлык тукымалар һәм кием-салымнар да янып беткән, бернәрсә дә калмаган. Бик зур кайгыга батып, сәүдәгәр өенә кайтып керә. Хатынына булган хәлләрне сөйләп бирә: «Минем кибетем көлгә әйләнде, мин бөлгенлеккә төштем». Хатыны ирен тынычландырырга теләп: «Кайгыга бирелмә, Аллаһының ярдәмендә шикләнмә. Аллаһы Тәгалә сиңа хәерлесен насыйп итәр, тыныч бул», – дип юата. Ярсыган ир хатынына болай дип җавап кайтара: «Ул хәерлелек килгәнче, бар син, атаң йортына кайтып тор. Мин сине тәэмин итә алмый». Озак та тормый, ул хатынын аера.

Аллаһы Тәгалә хатынны ярдәменнән ташламый, ул башка берәүгә кияүгә чыга. Бу ире исә бик юмарт, көнчесезләрне кызганучы, ярлыларга һәм мохтаҗларга кулыннан килгән кадәр ярдәм итүче кеше була.

Көннәрнең берсендә, бу хатын ире белән ашап утырган вакытта ишеккә шакыйлар. Хатын кем шакыганны белергә теләп барып карый. Ул иренә: «Анда бер ярлы, аның тамагы ач һәм ул азрак булса да ризык сорый», – дип әйтә. Ире аңа: «Аңа ике тавыкның берсен бир. Безгә икебезгә калганы да җитә. Аллаһы Тәгалә безгә тагын бирер, ярдәм сораган кешене кире какмыйк», – дип җавап кайтара. Хатыны моңа бик канәгать булып: «Синнән дә мәрхәмәтле һәм юмарт кеше юктыр», – дип шатлыгын белдерә. Ул ире кушканча бер тавыкны ярлыга тапшыра. Янәдән өстәл артына утырганда хатынның күзләре яшьләнгән була. Моны ире дә күреп ала һәм гаҗәпләнеп хатыныннан: «Нәрсә булды? Син нигә елыйсың?» – дип сорый. «Мин кайгыдан елыйм», – дип әйтә хатыны. Ире моның сәбәбен белергә тели. Хатыны аңа: «Әле яңа гына безнең ишекне каккан һәм син тавык биреп чыгарган кеше – ул минем беренче ирем иде! Шуннан соң хатыны элекке иренең ничек саран булуын һәм бервакыт ризык сорап, ишек каккан ярлыны ямьсез сүзләр әйтеп куып чыгаруын сөйләп бирә. Бу вакыйгаларны тыңлап бетергәннән соң, ире хатынына болай дип әйтә: «Хәзер генә безнең ишекне каккан ярлы кеше ул синең беренче ирең булса, моннан берничә ел элек ирең куып чыгарган ярлы – ул мин идем».

# Бәрәкәтнең сере нәрсәдә?

Халид бине Вәлид тапшырган хәдистә әйтелә: бервакыт Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам янына бер гарәп килеп: «Ий, Аллаһының Илчесе, мин синнән бу дөньяда бәрәкәт җитсен өчен ниләр эшләргә кирәклеген сорарга килдем», – дип әйтте.

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам шунда: «Син сора, мин җавап бирермен», – дип әйтте.

– Иң гыйлемле кеше булырга телим.

– Аллаһы Тәгаләдән курык, шулвакыт иң гыйлемле кеше булырсың.

– Иң бай кеше булырга телим.

– Аллаһы сиңа биргәннәрдән канәгать бул, шулвакыт иң бай кеше булырсың.

– Иң гадел кеше булырга телим.

– Башкаларга да үзеңә теләгәннәрне телә, шулвакыт иң гаделе булачаксың.

– Иң игелекле кеше булырга телим.

– Син кешеләргә файда китерүче бул, шулвакыт иң игелекле булырсың.

– Аллаһы каршында үзенчәлекле булырга телим.

– Син Аллаһыны күбрәк зикер ит, шулвакыт Аллаһы каршында да үзенчәлекле булырсың.

– Камил иманлы булырга телим.

– Холкың өстендә эшлә, аны яхшырт. Шулвакыт иң камил иманлы булырсың.

– Тәкъва булырга телим.

– Син, Аны күргәндәй гыйбадәт кыл; син Аны күрмәсәң дә, Ул сине күрә.

– Аллаһыга буйсынучы булырга телим.

– (Аллаһы) кушканнарын үтә, буйсынучы булырсың.

– Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә мине югары дәрәҗәләргә күтәрүен телим.

– Кешеләргә карата каты күңелле булма, Аллаһы сине югары дәрәҗәләргә күтәрер.

– Аллаһы Тәгалә Кыямәт көнендә миңа карата мәрхәмәтле булуын телим.

– Үзеңә һәм калганнарга карата да рәхимле бул.

– Гөнаһларымның азаюын телим.

– Тәүбәләреңне арттыр һәм гөнаһларың да кимер.

– Намуслы кеше булырга телим.

– Кешеләргә үз эшләрең турында зарланма.

– Бөтен кешедән дә көчле булырга телим.

– Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыл, иң көчлесе булырсың.

– Аллаһы Тәгалә ризыгымны арттыруын телим.

– Һәрвакыт тәһарәтле йөр.

– Аллаһы Тәгаләнең Кыямәт көнендә миңа ачуланмаячагына ышанасым килә.

– Аллаһы Тәгаләнең бер мәхлугына да ачуланма.

– Аллаһы Тәгаләнең догаларыма җавап бирүен телим.

– Тыелган гамәлләрдән ерак бул, шулвакыт Аллаһы да догаларыңа җавап бирер.

– Аллаһы Тәгаләнең Кыямәт көнендә минем җитешсезлекләремне яшерүен телим.

– Кардәшләреңнең хаталарын яшер.

– Гөнаһлардан һәм хаталардан нәрсә саклый ала.

– Күз яшьләре, буйсынучанык һәм авырулар.

– Аллаһы Тәгалә каршында иң изге гамәлләр нинди?

– Күркәм холык, тыйнаклылык һәм кайгыларга сабыр булу.

– Аллаһы Тәгалә каршындагы иң начар гамәл нинди?

– Начар холык һәм саранлык.

– Бу һәм теге дөньяда Аллаһы Тәгаләнең ачуын нәрсә баса?

– Яшерен садака бирү һәм талашканнарны дуслаштыру.

– Кыямәт көнендә җәһәннәм утын нәрсә сүндерә ала?


– Кайгыларга һәм хәсрәтләргә түземлек.

– Аллаһы Тәгаләнең һәм Аның Пәйгамбәренең яраткан бәндәсеннән булырга телим.

– Аллаһы Тәгалә һәм Аның Пәйгамбәре яратканнарны ярат.

# Кадаклар

Бер ярсу холыклы малай яшәгән. Көннәрдән бер көнне әтисе аңа кадаклар салынган кечкенә капчык бирә. Ярсуы кабынган саен ул аңа бер кадак алып, шуны киртәгә кадакларга куша. Беренче көнне үк киртәдә 37 кадак сугылган була. Икенче атнага малай акрынлап үзенең ярсуын басарга өйрәнә һәм киртәгә сугылган кадакларның саны да азая. Шул рәвешле, малай кадак сугуга караганда, үз холкыңны тәрбияләүнең җиңелрәк булуын аңлый башлый. Ниһаять, бер көнне малай бөтенләй дә холыксызланмый, тәртип бозмый. Ул бу шатлыгын әтисенә сөйли. Әтисе бу юлы улына болай дип киңәш бирә: «Әгәр син ачуыңны һәм ярсуыңны тыеп кала алсаң, ул очракларда бу киртәдән сугылган кадакларны алырсың». Күпмедер вакыт үткәннән соң, малай әтисе янына килеп, киртәдә бернинди кадак калмавы хакында хәбәр итә. Әтисе улын кулларыннан тотып, киртә янына алып килә һәм улына: «Син булдыргансың, ләкин күрәсеңме, киртәдә күпме ярыклар? Бу киртә беркайчан да элеккеге кебек булмас. Әгәр дә кешегә начар сүз әйтсәң, анда да бу ярыклар сыман яралар, эзләр кала. Син аннан күпме генә гафу үтенсәң дә – эзләр калачак. Тел белән әйтелеп ясалган эзләр тән ярасы кебек үк нык авырта. Чын дуслар күп булмый. Алар шатлыкларыңны бүлешә, авыр вә кайгылы вакытларында сиңа ярдәм кулы суза. Аларны кадерлә», – дип киңәш бирә.




Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм «Хозур» нәшрият йорты **«Галимҗан Баруди һәм аның хезмәтләре»** дип аталган китап нәшер итте.

Китапта Г. Барудиның тормыш һәм хезмәт юлы, аның дини һәм дөньяви әсәрләре, кыскача ул нәшер иткән дини журнал тасвирлана. Китап киң җәмәгатьчелеккә, шулай ук һөнәри дини мәдрәсәдә укучылар һәм дини оешмаларда эшләүче дин әһелләренә өстәмә дәреслек буларак тәкъдим ителә.

Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алып була.

**Кибетләрнең адреслары:**
- Тукай урамы, 36 йорт;
- Газовая урамы, 14 йорт.

**Белешмәләр өчен телефон:**
+7 (903) 388-86-33.




**«Дин вә мәгыйшәт» газетасына 2019 елның икенче яртысына язылу башланды**

- Ярты елга язылу бәясе: 132 сум
- Газета айга бер тапкыр чыга
- Язылу индексы: П4333

Түбәндәге сайтларда да язылу мөмкин:
podpiska.pochta.ru һәм uslugi.tatarstan.ru сайтының «Подписка» бүлегендә.

дин вә мәгыйшәт

Белешмәләр өчен телефон: 598 09 42

## КАЗАН ӨЧЕН ИЮНЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.06.2018 | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 12:00 | 17:24 | 20:16 | 21:46 |
| 02.06.2018 | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 12:00 | 17:24 | 20:17 | 21:47 |
| 03.06.2018 | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 12:00 | 17:25 | 20:18 | 21:48 |
| Ураза гаете белән! | | | | | | | |
| 04.06.2018 | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 12:00 | 17:26 | 20:20 | 21:50 |
| 05.06.2018 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:26 | 20:21 | 21:51 |
| 06.06.2018 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:27 | 20:22 | 21:52 |
| 07.06.2018 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:23 | 21:53 |
| 08.06.2018 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:28 | 20:24 | 21:54 |
| 09.06.2018 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:29 | 20:25 | 21:55 |
| 10.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:29 | 20:26 | 21:56 |
| 11.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:27 | 21:57 |
| 12.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:30 | 20:28 | 21:58 |
| 13.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:28 | 21:58 |
| 14.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:31 | 20:29 | 21:59 |
| 15.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 16.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:30 | 22:00 |
| 17.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:32 | 20:31 | 22:01 |
| 18.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 19.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:31 | 22:01 |
| 20.06.2018 | 00:57 | 01:27 | 02:57 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 21.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:33 | 20:32 | 22:02 |
| 22.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 23.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 24.06.2018 | 00:58 | 01:28 | 02:58 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 25.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 26.06.2018 | 00:59 | 01:29 | 02:59 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 27.06.2018 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 28.06.2018 | 01:00 | 01:30 | 03:00 | 12:00 | 17:34 | 20:32 | 22:02 |
| 29.06.2018 | 01:01 | 01:31 | 03:01 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 30.06.2018 | 01:02 | 01:32 | 03:02 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
*Май саны, №5 (286)*

Баш мөхәррир: **Нәширбанов И.К.**
Мөхәррир: **Маннанова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
**Булат МӨБӘРӘКОВ;**
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2749
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Индексы – П4333. Казан шәһәренең мәчетләрендә 28 нче маенда таратыла.
График буенча бу санга 27 нче май көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.